• ВАКЫЙГА •

### ГАЗЕТАГА ЯЗЫЛУ ДӘВАМ ИТӘ!

*2018 елның 2 яртысына язылу бәясе - 132 сум.*
*Язылу индексы: П4333*

• СОРАУ-ҖАВАП •

### ХӘРАМ БУЛАЧАК ТУЙГА БАРЫРГА ЯРЫЙМЫ?

*Сорауга Татарстан мөфтиенең җавабы*

*7 бит*

• МӘГАРИФ •

### МӘДРӘСӘЛӘР СОЛТАНЫ – «МӨХӘММӘДИЯ»

*Мәдрәсәнең тарихы, күренекле шәкертләре, бүгенгесе.*

*9 бит*

• ҮРНӘК ЗАТЛАР •

### МӨЭМИННӘРНЕҢ ӘМИРЕ – ГОМӘР

*Гомәр бине Хаттабның тормыш юлы, сыйфатлары хакында*

*12 бит*

*№ 6 (275)* *Татарстан мөселманнары диния нәзарәте басмасы* *Рамазан - Шәүвәл 1439*

*Июнь, 2018*

دين و معيشت

ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ

# Мөфти Казан FIFA матбугат үзәгендә: «Көчле мөселман Аллаһы Тәгалә каршында көчсез мөселманга караганда яхшырак”



# Голәмәләр дини йолалар турындагы Нигезләмәне яңартачак

21 июнь көнне Казанда ТР МДН Голәмәләр Шурасының чираттагы утырышы булып узды. Көн тәртибендәге төп сорау «Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә»не яңарту иде. Документ Нәзарәтнең Голәмәләр шурасы һәм Казыйлар шурасы тарафыннан 2014 елда эшләнде һәм Татарстанның барлык имамнарына куллану өчен җибәрелгән иде. Брошюрада мөселман гореф-гадәтләре турындагы иң актуаль сорауларга җаваплар китерелгән, шунлыктан ул Татарстандагы барлык имамнар өчен дә өстәл китабына әйләнгән. Әмма Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның боерыгы белән әлеге басманы бүгенге көн вәзгыятеннән чыгып яңарту турында карар кылынды. Мисал өчен, Нигезләмәдә никах һәм талак турындагы бүлекләргә төгәллекләр кертеләчәк. Голәмәләр шурасының әлеге утырышында бу хезмәтне башкару өчен төркемнәр булдырылды. Аларның эшенә казыйлар, галимнәр, шәригать өлкәсе белгечләре җәлеп ителде. Яңартылган документны агымдагы елның сентябрендә эшләп бетерергә планлаштырыла.



Голәмәләр шурасы – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең киңәшмә органы, махсус рәвештә фәнни-дини өйрәтмә мәсьәләләрен өйрәнү һәм чишү максатыннан булдырылган. Голәмәләр шурасы бүгенге көндә Татарстан һәм Россия өммәте социаль-икътисади үсешенең өстенлекле юнәлешләрен тормышка ашыруда актив катнаша.

2017 елда Голәмәләр шурасы эшчәнлеге банк, инвестиция һәм социаль өлкәләрне күздә тотты, шулай ук дини йолалар һәм тәҗрибәләр буенча мәсьәләләрне карады. Голәмәләр тарафыннан төрле эзләнүләр алып бару һәм рәсми нәтиҗәләр чыгару Татарстан һәм Россия күләмендә зур әһәмияткә ия берничә проект тормышка ашырыла. Алар арасында – «АК БАРС» БАНК ААҖ белән уртак ислам канунннары буенча финанс хезмәтләр һәм хәләл продукция җитештерү өчен аерым технологияләр. Моннан тыш, Шураның эш төркеме тарафыннан торак-төзелеш кооперативлары, иминиятләштерү компанияләре эшчәнлекләре анализланды, мөселман календареның истәлекле бәйрәм көннәре билгеләнде, дини йолалар стандартлаштырылды, имамнар һәм казыйлар өчен никахларны теркәү һәм талак мәсьәләләре буенча кагыйдәләр җыентыгы бастыру өчен әзерләнде.

Татарстан голәмәләре эшчәнлеге чит илләрдә югары бәяләнүен шулай ук Шура әгъзасы Рөстәм хәзрәт Нургалиевның фәтвалар буенча Евразия ислам советының рәис урынбасары булып сайлануы да күрсәтә.

■ **dumrt.ru**

# «Кәгазьгә яңа тормыш бүләк итик» хәйрия акциясе

Диния нәзарәте тарафыннан игълан ителгән «Кәгазьгә яңа тормыш бүләк итик» хәйрия акциясенә йомгак ясалды. Диния нәзарәте быел аны дүртенче тапкыр оештырды.

Акция кысаларында 20 көндә барлыгы 11,8 тонн макулатура тупланды. Хәйрия чарасында волонтерлар актив катнашты, алар кирәк булмаган кәгазьләрне җыю, бушату, үлчәү кебек эшләрдә ярдәмче булдылар.

Кирәк булмаган кәгазьләрне тапшырырга казанлылар гына түгел, Татарстан районнарында яшәүчеләр дә кушылды. Аеруча Татарстанның мөхтәсибәтләре - Аксубай, Кайбыч, Лаеш, Чистай, Кукмара, Әгерҗе, Буа, Алабуга, Әлки, Лениногорск, Сарман, Тәтеш, Бөгелмә, Чүпрәле, Ютазы, Саба мөхтәси-бәтләре һәм Казан шәһәренең Мәскәү, Киров, Совет районы мөхтәсибәтләре зур активлык күрсәтте.

Акция хәйриячеләре арасында шулай ук оешмалар да бар. Мисал өчен, ҖЧҖ «Транснефть-саклык» төньяк-көнбатыш төбәкара идарәсе филиалы ярты тоннага якын макулатура тапшырды.

Республика районнарыннан җыелган гомуми макулатура күләме 9,6 тонна тәшкил итте. Казанның Тукай урамында урнашкан Галиев мәчетендә 2,2 тонна кәгазь чималы тупланды. Акция кысаларында җыелган чаралар матди ярдәм күрсәтү максатыннан «Зәкәт» хәйрия фонды карамагындагы авыру балаларны дәвалау өчен тапшырылачак.

■ **dumrt.ru**

# VII Әтрәч укулары

Тәтеш районы Зур Әтрәч авылында VII Әтрәч укулары уздырылды. Әлеге чараның төп максаты – татар халкының гореф-гадәтләрен саклау. Быелгы Әтрәч укулары да Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте, ТР Фәннәр академиясе, ТР Дәүләт Советы, Тарих һәм Археология институты вәкилләре, галимнәр катнашында үткәрелде. Укуларның темасы «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел» дип аталды.



Әлеге җирлектә XII-XIII гасырларга караган зиратта борынгы кабер ташлары саклана. Быел да кайткан кунаклар әлеге каберстанга килеп Коръән укып, күмәк догалар кылу чарасында катнаштылар. Аннары чишмә янында мәҗлес уздырылды, дин әһелләре, галимнәрнең чыгышлары тыңланды. Кунакларны Татарстан мөфтие исеменнән Нияз хәзрәт Сабиров сәламләде һәм изге гамәлләр кылуны Рамазан аеннан соң да дәвам итү турында вәгазь сөйләде. Тарихчылардан Наил Таиров, Сөләйман әфәнде Рәхимов, Эльмира ханым Сәлахова, археолог Радион әфәнде Хәмзин чыгыш ясады. Тәтеш районы башлыгы Рәмис Сафиуллов әлеге чараны оештыручыларга, аерым алганда, Диния нәзарәтенә рәхмәтләрен җиткерде. Җәмәгать белән берлектә өйлә намазы укылды, Кече Әтрәч авылында хәләл Сабантуй үткәрелде.

Укуларны оештыруда Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе зур өлеш кертте. Мәдрәсә мөдире Ильяс хәзрәт Җиһаншин киләчәктә укуларда тарихны белү буенча бәйгеләр оештыру тәкъдимен җиткерде.

■ **dumrt.ru**

# Чаллы Җәмигъ мәчете төзелеше

Чаллы Җәмигъ мәчете төзелеше быел да дәвам итәчәк. 18 июньдә Чаллы мөхтәсибәтендә узган Җәмигъ мәчете төзелеше Попечительләр шурасы утырышы йомгаклары шулай дип нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Ошбу хакта шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин болай ди: «Аллаһның рәхмәте белән Попечительләр шурасының чираттагы утырышын үткәрдек. Аны шура рәисе, шәһәребез мэры Наил Гамбәр улы Мәһдиев алып барды. Көн тәртибенә берничә мәсьәлә куелган иде. Аның беренчесе узган елгы эшләр буенча хисап тоту булды. Хисапны Җәмигъ мәчете төзелешенә финанс ярдәме күрсәтү фонды җитәкчесе Уел Галим улы Хөсәенов ясады. Узган ел бинаның идән асты өлешен тәмамлау бурычы куелган иде. Аллаһка шөкер, аны тәмамлап, җир өстенә чыктык. Ел әйләнәсендә 26 млн. сумлык төзү-монтаж эшләре башкарылды. Бер үк вакытта проектны камилләштерү эшләре барды. Башкарылган эшләр канәгатьләнерлек дип табылды. Инде Аллаһ насыйп итсә, акчаларыбыз пәйда булса, төзелешне быел да дәвам итәргә ниятебез бар. Бу мөмкинлек турында сөйләшү булды. Максатыбыз – монолит стеналарны күтәрә башлау. Ул чагында мәчет төзелеше күзгә дә күренә башлар иде. Чөнки моңача барлык эшләр җир асты өлешендә барды. Ә стеналар күтәрелеп, халык күрә башласа, төзелешкә ярдәм итү теләге дә үсәр иде. Шулай ук быел алдыбызда торган бурычларның берсе – проектлау эшләрен тулысынча тәмамлау.



Шура утырышы вакытында аның составы яңа әгъзалар белән тулыландырылды. Тәкъдим ителгән яңа әгъзалар бертавыштан кабул ителде. Финанс ярдәме җәлеп итү буенча җитәкчеләр, халык белән активрак эшләү, төзелешне активлаштыру өчен булган бөтен көчне туплау мәсьәләсендә фикер алышындык».

# Мөселман балалар сабан туена рәхим итегез!

2018 елның 15 июлендә Балтач районының Бөрбаш авылында Республикакүләм мөселман балалар сабан туе уздырылачак. Бик күп кунаклар, хөкүмәт вәкилләре, дин әһелләре, күренекле шәхесләр катнашында уздырыла торган әлеге күркәм чара быел унберенче тапкыр Балтач районы имаммөхтәсибе, Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыевның тырышлыгы белән оештырыла. Сабантуйда шулай ук чит төбәкләрдән дә мөселман дини оешма вәкилләре: Ульян, Самара, Киров өлкәсе, Мари Эл, Чувашия республикалары мөселманнарының да кунак булуы көтелә. Сабан туена килүчеләрнең һәммәсе баш киеменнән – ир-атлар түбәтәйдән, хатынкызлар яулыктан булалар. Өйлә вакыты җиткәч җәмагать белән намаз укыла. Узган елны бәйрәмгә килгән кунакларны сыйлау өчен ун чиләкле ун казан пылау пешерелде.



Сабантуй балаларның Коръән һәм догалар укулары, мөнәҗәт әйтүләр, шигырьләр белән үрелеп барачак.

Бәйрәм кысаларында балалар өчен төрле уеннар, ярышлар, рухи кыйммәтләрне барлаучы чаралар оештыру каралган. Моңардан тыш, 35, 50, 65 килограммга кадәрге һәм аннан югарырак үлчәү категорияләрендә балалар арасында көрәш бәйгесе булачак. Абсолют батырга – скутер, беренче урынга – тиз йөрешле велосипед, калган урыннарны яулаучыларга велосипедлар бирелә-чәк. Моннан тыш, сабантуйда төрледән-төрле 17 ярыш оештырылачак.

Башлана сәгать 10да (Балтач районы, Бөрбаш авылы).

# Дөнья Чемпионаты көннәрендә мөфти Австралия татарлары белән очрашты



ТР мөселманнары Диния нәзарәтенә Татарстан мөфтие белән очрашуга Австралиянең татар-башкорт җәмгыяте рәисе Шөһрәт Вәли килде. Ерактан килгән кунак Камил хәзрәткә үзенең сәфәре турында сөйләде: «Без Казан шәһәрендә уза торган футбол буенча дөнья чемпионатын карарга килдек. Татарстан башкаласында моңа кадәр дә булганыбыз бар иде. Аллаһка шөкер, республика башкаласы бик тә үзгәргән, матурайган, зурайган». Татарстан мөфтие татарларның яшәеше турында сорашты. «Милләттәшләребез белән аралашып торабыз.

Аделаида шәһәрендә татар мәчете эшли, вәгазьләребез бары татар телендә алып барыла, балаларыбызга татар телен, дин нигезләрен өйрәтәбез. Футбол чемпионатына Казанга барлыгы егерме мең австралияле килде, шуның утыз өче безнең милләттәшебез. Россиядә татар һәм инглиз телләрендә аралаштык, хәзер кириллицаны, русчаны өйрәнәбез. Сезне киләчәктә Австралиядә кунак буларак күрүебезгә шатбыз», – дип белдерде Австралия татарлары җитәкчесе. Камил хәзрәт үз чиратында кунакны Диния нәзарәтенең туган телебезне саклауга һәм үстерүгә багышланган проектлары белән таныштырды, «Хозур ТВ» каналы эшчәнлеге турында сөйләде.

Мөфти хәзрәт очрашу ахырында татар телендә дини әдәбият бүләк итте.

Кунаклар әлеге бүләкләр өчен Татарстан Диния нәзарәтенә һәм «Хозур» нәшриятына рәхмәтләрен җиткерделәр.

# Картлар йорты – җәмгыятьнең зәгыйфьлеге

Һәр ата-ана баласының күзләрендә шатлык кына түгел, үзенең дәвамын да, картлык көнендә ризыкландыручысын да күрергә тели. Әмма моның өчен бала күңеленә тиешле орлыклар чәчәргә кирәк. Баланың мөстәкыйльлеге, әти-әнисенә картлык көнендә җылы мөнәсәбәте – ата-ананың тәрбия нәтиҗәсенә бәйле.

Факиһ (Аллаһ аннан разый булсын) болай дип әйткән: «Әгәр дә Аллаһы Тәгалә Үзенең китабында хәтта ата-аналарга итагать итәргә боермаган булса да, моның һәркемгә фарыз булуы акыл көче белән дә аңлашылыр иде. Аек акыллы кешегә ата-ананың бөеклеген аңлау һәм аларга карата булган бурычларны үтәү вәҗиб булып тора. Аллаһы Тәгалә бар китапларында да (Тәүрат, Инҗил, Зәбур, Коръән) һәм барлык пәйгамбәрләренә дә ата-ананы хөрмәт итәргә боерды».

Әгәр әти-әни баласыннан канәгать булса, Аллаһ та аннан канәгать булыр. Һәм әгәр ата-ана баласына ачуланса, Аллаһы Тәгалә дә бу кешегә ачуланыр. Коръәннең өч аятендә Аллаһның бер әмерен үтәмәү, икенче әмерне кабул итмәүгә китерә, дип әйтелә. Беренче аять: **«Намазларны үтәгез һәм зәкәт бирегез»** («Әл-Бәкара / Сыер», 2:43). Әгәр кеше, намаз укып та зәкәт түләмәсә, аның намазлары кабул булмаячак. Икенче аять: **«Аллаһка һәм Аның расүленә итагать итегез»** («Әли Гыйммран / Гыйммран гаиләсе», 3:132). Адәм баласы Аллаһка буйсынып, Пәйгамбәребез галәйһиссәләмгә итагать итмәсә, Аллаһка буйсынуы кабул булмаячак. Өченче аять: **«Миңа һәм ата-анаңа шөкер ит»** («Локман», 31:14). Кеше Аллаһка шөкер итеп, әти-әнисенә рәхмәтле булмаса, Аллаһка булган шөкерләре кабул ителмәячәк.

Һәрбер мөэмин мөселман үзенең газиз ата-анасына карата миһербанлы, шәфкатьле булырга тиеш. Аллаһы Тәгалә Коръәндә моның турында болай әйтә:


**«Үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, аннары: ата-анага изгелек итегез. Тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһ, әлбәттә, сөйми!»**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Мөселман кешесе үз әти-әнисенә, хатынына һәм балаларына карата гына игелек һәм мәрхәмәт белән чикләнми, ә туганнарына да шундый ук мөгамәлә күрсәтә, алар белән тыгыз мөнәсәбәтләр урнаштыра. Ислам дине аларга карата яхшы мөгамәләдә булырга куша, туганнары белән мөнәсәбәтне сакларга өнди һәм әлеге мөнәсәбәтләрне өзүчеләргә зур җәзалар вәгъдә итә.

Ләкин, шуңа да карамастан, адәм баласы еш кына әлеге кагыйдәләргә колак салмый. Ни кызганыч, моңа бәйле гыйбрәтле хәлләрне әледән-әле ишетеп торабыз. Газиз балаларын үзенчә тырышып тәрбияләгән ата-аналарның үсеп, зур кешеләр булган балаларына кирәкләре калмый, аларны өйләреннән куып чыгаралар. Ялгыз калган ана: «Балаларымны үстергәндә, күкрәк сөтемне имезгәндә, балаларыма байлык теләдем. Әлбәттә, Аллаһы Тәгалә сүземне ишетте, догамны кабул кылды, алар зур кешеләр булдылар, ә мин шушы хәлгә төштем. Мин балаларыма байлык теләгәнмен, ә Аллаһы Тәгаләдән миһербан-шәфкать ияләре булуларын сорамаганмын», – ди.

Баланың киләчәге, аның булачак әхлагы ата-аналарның да тәрбияләреннән тора. Бу уңайдан бер вакыйга хәтергә килә. Бер ата үзенең улын иярттеп, картайган атасын арбага салып, авыл читенә юнәлә. Билгеле инде, максатлары – атасының әҗәлен якынайту була. Мескен картны тәгәрәтеп



җибәргәч, ата үзенең улына карап: «Улым, бабаңны ташладык, инде арбаны да ташлыйк», – ди. Улы: «Юк, әтием, арбаны кирәге чыгар әле, синең дә картаясы көнең бар бит», – дип җавап бирә. Димәк, һәрбер мөнәсәбәт кире әйләнеп кайтачак.

Адәм баласы мондый хәлгә калмасын өчен Исламда бик күп өйрәтмәләр бар. Динебез тормышның һәр мизгелен үз эченә ала.

Балалар кеше тормышына шатлык китерәләр, аны күңелле итәләр, аларның бәрәкәтләре ярдәмендә шәфкатьлелек барлыкка килә һәм уңышлар арта. Ләкин моның барысы да турыдан-туры яхшы тәрбия һәм алардан тәкъва буын үстерү белән бәйле. Кеше үз балаларында әлеге сыйфатларны тәрбияли алса, балалар аның фани тормышының чын бизәкләренә әвереләләр. Әгәр ата-аналар бала тәрбияләүгә тиешле игътибар бирмәсәләр, балаларын һәрвакыт дөресләп тормасалар, ул вакытта бала бәлага әйләнә, хәерсез җәзага әверелә, йокысыз, тынгысыз төннәр булып кала.

Акыллы, хакыйкый мөселман үстергән балалары өчен зур җаваплылык алганын аңлый, чөнки ул түбәндәге Коръән аятен белә:

**«Әй, иманлы бәндәләр, утын урынына кешеләр һәм ташлар ягылган җәһәннәмнән үзегезне һәм гаиләгезне саклагыз. Ул җәһәннәмгә билгеләнгән газап фәрештәләре бар, алар җәһәннәм әһеленә каты сүзле, каты куллы, газап кылуда бик куәтлеләрдер. Алар үзләренә булган боерыкларда Аллаһка һич хилафлык кылмаслар, Аллаһтан нинди боерык булса – шуны эшләрләр».**

«Тәхрим / Тыю», 66:6

Чынлап та, Ислам дине ата-ананы балаларының тәрбиясе өчен җаваплы итә. Ул тәрбия тулысынча Ислам рухына һәм күркәм холыкка нигезләнергә тиеш.

Гаилә – кош балаларының оясы. Анда аларга каурыйлар чыга, алар җитлегәләр, ул алар үсә торган яшәү мохите, үзенчәлекләрен, холыкларын һәм шәхесләрен формалаштыра торган тирәлек. Моннан аңлашыла да, ата белән ана бу әле чәчәк атмаган бөреләрне карау эшендә зур роль уйныйлар, аларга тиешле юнәлеш бирәләр. Болар исә, үз чиратында, акылга, рухка һәм тәнгә гармоник рәвештә үсеш алырга ярдәм итә.

Акыллы мөселман ата-аналары балаларын формалаштыру эшендә иң яхшы ысуллар кулланалар, аларның психологик үзенчәлекләрен беләләр, гөнаһсыз җаннарына тиешле юллар таба алалар. Алар балаларының мәхәббәтләрен төрле алымнар ярдәмендә яулыйлар, аларның үсеш дәрәҗәләрен һәм яшьләрен истә тотып якынаерга тырышалар, алар белән уйныйлар, шаяралар, мактыйлар, мәхәббәт һәм ярдәм сүзләре әйтәләр. Үзенә карата мондый мөнәсәбәтне күргән бала да әти-әнисен ярата. Моның нәтиҗәсендә ул дәртләнеп аларның үгет-нәсыйхәтләрен тыңларга риза була. Ә мәхәббәткә, хөрмәткә, югары бәяләүгә һәм ышанычка нигезләнгән буйсынучанлык кырыслыкка, мәҗбүр итүгә, изүләргә һәм төрле тыюларга корылган буйсынучанлыктан бик нык аерыла.

Беренче очракта даими, үзгәрми торган буйсынучанлык турында сүз бара. Икенче очракта, киресенчә, вакытлыча, зәгыйфь буйсынучанлык турында. Тыюлар, кыерсытулар тулысынча яки вакытлы гына туктатылса, ул юкка чыга. Кайбер кешеләр ата-аналар һәм балалар арасындагы аралашу гади булса, ул гадилек бала алдында аларның дәрәҗәләренә зыян китерә, тәрбияче буларак кимсетә, дип уйлыйлар. Бу тулысынча хаталы караш. Чынлыкта, балаларга карата мондый мөнәсәбәт зирәклекне күрсәтә һәм тәрбиянең уңышлы алымы булып тора. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмгә килгәндә, ул моңа үзенең сүзе һәм дә гамәлләре белән бик күп гасырлар элек чакырган.

Бүгенге көндә зәңгәр экраннардан карыйсыңмы, газета-журналлардан укыйсыңмы, тегеяки бу районда картлар йорты ачылган дип, шатланып хәбәр җиткерәләр, язалар. Бу бик аяныч хәл. Моңа сөенергә кирәкми, бу сөенерлек нәрсә түгел. Мондый күренеш нәрсәне аңлата соң? Җәмгыятебезнең зәгыйфьлеген күрәбез түгелме? Шушы дөньяда тагын да балаларына кирәкмәгән картлар-карчыклар артканны аңлата бит.

Аллаһы Тәгалә алга таба китерелгән аятьтә ата-аналар өчен дога кылу тәртибен өйрәткән һәм боерган:

«Аллаһ хөкем итте һәм әмер бирде: фәкать Аллаһка гына гыйбадәт кылырга һәм ата-анага изгелек итәргә. Әгәр син исән чакта аларның берсе яки икесе дә картлыкка ирешсәләр, син аларга «уф» та димә, һәм каһәрләмә, кәефләрен җибәрмә. Бәлки аларга һәрвакыт йомшак бул, мөлаем сүзләр сөйлә. Вә аларга шәфкать итеп, рәхимлек канатларыңны җәй! Һәм әйт: «Раббир-хәмһүммә кәмәә Раббәйәәнии сагыйра».

**«Йә, Раббым! Алар мине кечкенә чагымда мәрхәмәт белән үстергәннәре кебек, Син дә аларга дөньяда һәм ахирәттә шәфкать кыл!»**

«Бәни Исраил / Ягъкуб балалары», 17:24

Шушы дөньяларда яшәгән чакларыбызда ике зур гөнаһ бар. Берсе – имансыз яшәү, шушы якты дөньядан Аллаһның хозурына имансыз китү. Икенчесе – газиз ата-анага карата миһербансыз, шәфкатьсез булу. Бу сүзләр турында уйлансак, хәерле гамәлләр кылсак иде.

# Сәламәт булыйм дисәң, ешрак елмаегыз



Нәрсә ул елмаю? Мөселман кеше бу сорауга: «Елмаю – ул рәхимлелек билгесе, ул – Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнән калган күркәм традиция», – дип җавап бирер иде. Бик күп хәдисләр җыентыкларында елмаю турында түбәндәге хәдисне очратырга була: «Елмаю – ул һәркем үзенең якын кешесенә бүләк итә ала торган сәдака». Исегезгә төшерегез, Мөхәммәд пәйгамбәр авыр вакытлардан кала, һәрвакыт елмая торган булган. Моның турында һәрбер сира (тарих) китапларыннан укып, сәхабәләрнең әйтеп калдырган сүзләреннән белеп була. Елмайган кешегә карап нәрсә әйтеп була? Кешенең йөзендәге елмаюга карап, йөрәгенең чисталыгы, анда золым булмаганлыгы, күңеле пакь икәнлеген әйтеп була, ә бу исә кешеләр арасындагы мөгамәләне җайга сала, аларны бер-берсенә якынайта.

Мең елдан артык тарихы булган ислам дөньясында елмаю күркәм гадәт һәм әхлакның бер өлеше булып саналган. Кайбер кешеләр махсус елмаерга күнеккәннәр, бу эштә остарганнар. Сәхабәләр, тәбигыйннәр һәм аларга ияргән кешеләр дә Мөхәммәд галәйһиссәләмгә ияргәннәр, аның һәрбер сүзен тыңлап, шуны эшләү белән генә чикләнмичә, ул кылган гамәлләрне дә кабатларга тырышканнар. Ә Пәйгамбәребез бер генә гамәлен дә, бер генә хәдисен дә үзе уйлап әйтмәгән. Алар барыбер Аллаһы Тәгалә тарафыннан иңдерелгән сүзләр һәм гамәлләр булып саналалар. Димәк, сәхабәләр Аллаһы Тәгалә ярата торган гамәл кылганнар булып чыга. Ә диндә һәр гамәл ул кешегә рухи гына файда биреп калмыйча, физик якны яхшырту өчен дә күп өлеш кертә. Бүген без XXI гасырда яшибез һәм шуңа күрә елмаю турында тагын да күбрәк мәгълүмат әйтә алабыз. Шулай итеп, елмаю – ул сәламәтлек өчен дә бик кирәкле гамәл. Елмаю йөрәк тибешен акрынайта, вакытлыча кан басымын түбәнәйтә. Организмда эндорфиннар барлыкка килүгә, тәнебездәге авыруларны басып торырга сәбәп була.

## Елмаю – кешеләрнең арасын якынайта

Елмаю җәмгыятьтәге мөнәсәбәтләрне дә ныгыта. Ул психологик эффектларга бик бай, шуңа күрә социаль элемтәләрне дә, шәхесара конфликтларны җайга сала ала. Моның өчен кешеләрне елмаеп каршы алырга һәм елмаеп озатып калырга өйрәнергә кирәк. Берәр төрле ситуациядә елмаю атмосфераны җиңеләйтергә булыша ала, кеше турында беренчел фикерләрне яхшы итеп күрсәтә ала.

Исегезгә төшерегез әле: кунакларны каршы алганда иң беренче нәрсә эшлибез? Әлбәттә, елмаеп, сәлам әйтәбез. Ә кайсы кешегә аларны елмаеп каршы алулары ошамый икән? Аллаһы Тәгалә кешене эмоцияләргә бай зат итеп яраткан. Һәм без, иң беренче чиратта, социаль затлар, шуңа күрә кешеләр белән мөгамәләдән күп нәрсә тора. Ислам дине кешеләрнең мөгамәләсен: гаиләдәге мөхитне, күршеләр белән аралашуны, дуслар белән дуслар, туганнар белән туганнар җепләрен саклап, күркәм халләттә тотар өчен бик күп киңәшләр бирә. Елмаю – социаль мөгамәләне барлыкка китерергә, аны нык итеп тотып торырга ярдәм итә торган бик якшы коралларның берсе.

## Елмаю – ярдәм чыганагы

Елмая белгән кешеләргә ярдәм итүчеләр дә күбрәк, чөнки караңгы йөз белән йөргән кешегә караганда, кече күңелле булган кеше белән элемтәгә керергә җайлырак. Ә инде бер-береңә ярдәм иткәндә, син ул кеше белән тагын да якынаясың. Әлбәттә, ни өчен ярдәм елмайган кешеләргә ешрак иреша дигән сорауга җаваплар да күп була ала.

Без кешенең ихлас елмаюын аера алабызмы? Без ихлас елмаюга гына җавап кайтарабызмы? Бәлки бу каракаршы җавап кынадыр: сез миңа елмайдыгыз, ә мин сез мохтаҗ булган ярдәмне күрсәттем. Яки елмаю тудырган күңелле халәт безне калганнарга ярдәм итәргә этәрәме икән? Ничек кенә булмасын, елмайган кеше барыбер күбрәк ярдәм алуга ирешә.

Ярдәм итү ислам динендә иң савапны гамәлләрнең берсе. Юкка гына сәдака бирү, күршеләргә карата күркәм мөнәсәбәт, кардәшеңә үзеңә теләгән әйберне теләү динебездә алгы планнарга куелмый.

Бүген дөньяда да, республикабызда да бик күп чаралар уздырыла. Аларда бик күп волонтерлар катнаша. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, күршеләргә ярдәм итү, волонтерлыкта катнашу, иганәчелек белән шөгыльләнү шул эш белән шөгыльләнгән кешегә бик күп файда китерә һәм бу файда начар гадәтләрдән, мәсәлән, тәмәке тартуны ташлауга караганда да бик күпкә артыграк рәхәтлек биргәне ачыкланган.

Капма-каршы сөйләшкәндә үзегез дә сизмичә үзегезнең әңгәмәдәшегезнең хәрәкәтләрен кабатлаганыгызга игътибар иткәнегез бармы? Ә төркем эчендә ул алай ук булмаска да мөмкин. Әмма әңгәмә вакытында ничә кеше булуына карамастан, сөйләгән кеше елмайса, калганнар да шуңа кушыла башлый. Бу исә чылбырсыннан реакциягә китерә. Димәк, сез калган кешеләргә дә яхшы йогынты ясый аласыз, бераз гына тырышырга кирәк.

**«Аллаһның Үзенә генә ихлас гыйбадәт кылыгыз, Аңа һичкемне, һичнәрсәне тиңдәш кылмагыз, аннары: ата-анага изгелек итегез һәм якын кардәшләргә, ятимнәргә, мескеннәргә, кардәш булган күршеләргә һәм кардәш булмаган күршеләргә дә изгелек итегез. Шулай ук сәфәрдә ят юлдашларга, үзегезгә кунак булып килгән юлчыларга һәм хезмәтче колларыгызга изгелек итегез. Тәкәбберләнеп мактанучыны Аллаһ, әлбәттә, сөйми!»**

«Нисә / Хатыннар», 4:36

Елмаючы кеше киң күңелле, эчкерсез, калганнарга ярдәмчел кеше булып күз алдына килеп баса.

## Елмаюмы, эмоцияме?

Бүгенге көн галимнәре тагын бер төрле дилемма алдында калдылар: беренче нәрсә туган – елмаюмы әллә эмоцияме? Тикшеренүләр үткәргәннән соң, елмаюның ниндидер шатлыклы вакыйгага реакция генә түгел, ә шул реакцияне тудыра торган фактор була алганын да ачыклаганнар.

Икенче төрле әйткәндә, безнең баш миебез шатлык хисләрен тойганда, битнең мускулларына елмаю өчен сигналлар җибәрелә. Бу мускулар баш миенә үзләре дә икенчел сигналлар җибәреп, баш миендәге шатлыклы тойгыларны тагын да көчәйтәләр. Безнең баш миебез үзендә бәхет хисләре тойганда, без елмаябыз, ә без елмайганда, безнең баш мие үзен тагын да бәхетлерәк хис итә.

Мичиган университеты галиме Роберт Зайонц елмаюның сәбәпләре һәм нәтиҗәсе дә аерым законнарга корылган, дип әйтә. Биттәге аерым бер мускулларның кыскаруы һәм йомшаруы аркасында баш миенә бара торган канның температурасы йә күтәрелә, йә төшә. Бу температура баш миенең эмоцияләр өчен җавап кайтара торган өлешенә турыдантуры тәэсир итә. Салкын баш мие яхшырак, ә җылы баш мие тискәре эмоцияләр чыгара икән.

Елмаю ихлас булмаса да, аннан файда бар икән. Безнең елмаю бернинди эмоцияләргә бәйле булмаса да, югарыда әйтеп узган процесс башланырга мөмкин. Хастаханәләрдә бер тикшеренү үткәргәннәр: пациентларның авызларына таякчыклар тыгып, аларны ясалма елмаерга мәҗбүр иткәннәр. Шуннан соң алардан кан алынган. Ясалма гына елмаю булса да, ул пациентлар 40 % кадәр авырту кимегәнлеге турында әйткәннәр.

Елмаю һәр кешегә килешә, ул беркайчан да артык булмый. Без шатлыклы вакытта чын күңелдән елмаябыз, кайгылы чакта авыр елмаеп та куя алабыз. Барысы да безнең өчен хәерле була. Пәйгамбәребез юкка гына елмаюны сәдака дип әйтмәгән. Без сәдаканы үзебездән башкаларга тиешбез. Ә елмаю, иң беренче чиратта, үзебезгә файдалы, шулай ук әйләнә-тирәбездәге кешеләргә дә күпме яхшы йогынтылар бүләк итә.

«Мин сезнең бу начар халәтегезнең нидән икәнен аңладым: сез артык җитди. Дөньядагы барлык акылсызлыклар да шушы артык җитдилек аркасында башкарыла. Елмаегыз, әфәнделәр, елмаегыз…», – дигән Карл Фридрих.

■ **Ленар Хамматов**

# Хәләл һәм хәрам




Галәмнәрне юктан бар итеп, аларны Үзенең хикмәте белән тәрбияләп торучы, безне шушы дөньяга төрле сынаулар белән сынар өчен җибәргән Аллаһы Тәгаләгә дан-мактауларыбыз булса иде. Шул сынауларны дөрес итеп үтәргә өйрәтер өчен җибәрелгән, мәэминнәрне җәннәт белән сөендергән, имансыз вә монафикъларны җәһәннәм белән кисәткән хак расүл Мөхәммәд галәйһиссәләмгә күңел түрләребездән чыккан салаватшәрифләребез булса иде.

Аллаһы Тәгалә Ислам динен, шәригатьне безгә акны карадан аерыр өчен, хәләлне хәрамнан аерыр өчен җибәрде. Ә нәрсә соң ул хәләл? Һәм нәрсә ул хәрам?

Кызганычка, безнең тирәлектә бу сүзләрнең мәгънәләре бик кыска формада гына таралган. Хәрам дип әйткәч, иң беренче, ризык күз алдына килә. Ризыктан да фәкать дуңгыз итен, эчемлекләрдән исә спиртлы эчемлекләр генә ярамый, дип уйлый халык. Ләкин бу төшенчәләр бик зур мәгънәгә ия.

Хәләл вә хәрам сүзе кешенең эшен, ашау-эчүен, хатта сөйләшүен дә үз эченә ала. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

**«Аллаһ сезгә сату-алуны рөхсәт итте һәм рибаны тыйды».**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:275

Монда Аллаһы Тәгалә эшмәкәрлекне рөхсәт итә, әмма процентлы риба эшләрен тыя. Бу – кешенең эшләү рәвешенә кагыла. Әгәр кеше эшлим дип, кемнедер рәнҗетеп, кемнеңдер малын урлап яки спиртлы эчемлекләр сатып мал туплый икән, аның тапкан малы хәрам дигән сүз. Расүлебез галәйһиссәләм бер хәдистә: «Аллаһы Тәгалә хәмерне, аны эчүчене, аны (стаканга) салучыны, аны сатучыны, сатып алучыны, аны эшләүчене, аны эшләтүчене, аны күтәреп йөрүчене һәм аны китерткән кешене ләгънәт кылды», – дип әйтте. Әлбәттә, үзен мөселман дип әйтүче кеше мондый эшләр белән шөгыльләнмәс.

Бүгенге җәмгыятьтә безне тагын бер куркыныч хәл көтә. Ул – никахсыз мөнәсәбәтләр. Бу – хәрам гамәлләрдер. Ә хәрам ул бик куркыныч нәрсә. Аның тәэсире башта ук булмаска да мөмкин, әмма күмпедер вакыт үтү белән чагыла башлаячак. Әйтик, кемдер гомере буе хәрам мал җыя, зур-зур йортлар төзи, тик картлыгында авырулары күбәя, балалары начар юлга керә, йортының бәрәкәте китә. Шул зур йортның бар сөенече, күңеллеге бетә.

Ислам динендә тагын бер тыелган гамәл – ул гайбәт. Аллаһы Тәгалә Үз китабында болай дип әйтә:

**«Тәхкыйк, хак мөэминнәр газаптан котылып, мәңгелек сәгадәткә ирештеләр. Алар намазларын хошугълык белән укыйлар. Янә алар буш сүзләрдән, файдасыз эшләрдән баш тарталар».**

«Әл-Мөэминүн / Мөэминнәр», 23:1-3

Гайбәт хакында бик күп хәдисләрдә әйтелә, кисәтелә. Пәйгамбәребез гайбәтнең нәрсә икәнен аңлатыр өчен беркөнне сәхабәләреннән болай дип сорады: «Беләсезме сез, нәрсә ул гайбәт?» Сәхабәләр: «Аллаһ һәм аның Расүле яхшырак белә», – дип җавап кайтардылар. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: «Үзенең мөселман кардәшенең яратмаган ягын искә төшерү», – дип әйтте. Сәхабәләр: «Әгәр дә мин булган ягын сөйләсәм?» – дип сорадылар. Ул болай дип җавап бирде: «Әгәр дә мөселман кардәшеңнең бозык бер гамәле бар икән, булганын сөйлисең икән, бу гайбәт булыр, әгәр дә булмаганны булды дип сөйләсәң, бохтан дип аталыр. Алар икесе дә бер хөкемдә булырлар».

Әлбәттә, намаз укучы мөселманнар хәрам эчемлек, ягьни хәмердән һәм гайбәттән ерак булса да, хәзер сөйләшеп китәсе мәсьәлә бик күп кешегә кагыла. Ул – ашау ризыгы. Безнең халыкта ашаудан фәкать дуңгыз ите генә тыелган дигән ялгыш фикер йөри. Әмма бу алай түгел.

Мал суйганда тиешле кагыйдәләр үтәлмәгән булса, бу ит тә кулланыр өчен хәрам була ала. Бу йорт кошларына да, кече мөгезле һәм олы мөгезле терлеккә дә кагыла. Мөселман кешесе хайванны чалган вакытта «Бисмилләһи, Аллаһу Әкбәр» дип әйтә икән, ягъни Аллаһ ризалыгын өмет итеп, Аның исеме белән чала икән, бу ит хәләл була. Коръәндә Аллаһ Раббыбыз болай дип әйтә:

**«Аллаһтан миңа вәхий кылынган Коръәндә ашау өчен ризык йөзеннән хәрам нәрсәне үлгән хайван, бугазлаганда аккан кан, дуңгыз ите һәм бугазлаганда Аллаһ исемен әйтмичә, башка берәр мәхлук исемен әйтеп бугазлаган хайван итен хәрам дип таптым»,** – дип әйт.

«Әнгәм / Терлек», 6:145.

Шуңа күрә мөселман кешесенә ит алганда, шушы критерийларга карарга кирәк. Кайвакыт итне хәләлме, дип сорагач: «Әйе, хәләл, авылдан китерелгән ит», – дип җавап бирәләр. Мондый җавап, әлбәттә, кешенең хәләл хакында белеме булмау аркасында гына була ала.

Кайвакыт: «Ит хәләл, хәрам була ала, ә менә кибетләрдә баллы ризык, печеньелар ник хәләл дигән билге белән була?» – дигән сорау бирәләр. Камыр ризыкларын пешергән вакытта аларга да хайваннарның эч майларын кушалар, шуңа күрә ул хайван да Ислам кануннары буенча чалынган булырга тиеш. Хәләл дигән ризыкта мөселманча чалынган хайван майлары кушыла.

Шулай ук төрле буяулар кушылып ясала торган ризыклар да бар, бу буяу махсус кортлардан ясала, әбҗәкләрне ашау Ислам динендә шулай ук тыела.

Күп кешегә хәрамны аңлата башлагач, ярсып: «Әби-бабайлар дуңгыз ашамаганнар һәм аракы эчмәгәннәр бит», – дип әйтәләр. Әйе, элекке буын заманында андый ризыклар булмаган, хайваннарны да алар хәләл итеп чалганнар. Хәләл ризык ашау ул бик мөһим, чөнки Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: «Кешенең карынына хәрам керсә, 40 көн буе кылган догасы, укыган намазы кабул булмас», – дип әйтә. Шуңа барча кардәшләргә әйтәсе килгән фикер – Рамазан айларында ифтарлар, бүтән мәҗлесләр үткәргәндә, изгелек эшлим дип, начарлык эшләмәс өчен, өстәлгә куясы ризыкны бик нык игътибар белән алырга кирәк.

Хәрам кергән карын авыру була, йөкле чакта хәрам ашаган ананың баласына начар тәэсир көчә ала. Шуңа күрә, газиз дин кардәшләрем, Аллаһтан хәләл тормыш сорыйк. Аллаһы Тәгалә шушы сөйләгәннәрдән файда алырга насыйп кылса иде.Тормышыбызда фәкать хәләл ризык, хәләл кәсеп кенә булып, хәрамнан тыелып яшәргә насыйп кылса иде.

■ **Алмаз Галимҗанов,**
**Саба районы имам-мөхтәсибенең**
**яшьләр эше буенча урынбасары**

Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең рәсми инстаграм битендә (@kamilhazrat) «хәләл» реклама стикеры белән дуңгыз итеннән ясалган продукциянең сатуга чыгуы хакындагы хәл турында үз фикерен белдерде:

«Моннан берничә көн элек Татарстан Республикасында «Челны мясо» компаниясенең футбол буенча дөнья Чемпионаты уңаеннан «хәләл» язулы реклама стикеры беркетелгән дуңгыз итеннән җитештерелгән ит продукциясен сатуга чыгаруы күп шау-шу күтәрә. Бу чын мәгънәсендә мөэмин-мөселманнарга, иманлы халыкка карата җинаять дияргә була һәм шул ук вакытта бу вакыйга барлык хәләл индустриясенә карата шөбһә уята.

«Хәләл» комитет белгечләре килеп чыккан ситуациядә тиз арада продукцияне сәүдә нокталарыннан алуда ярдәм итте, соңрак предприятиедә тикшерү эшләре оештырды һәм җаваплы затларга карата тиешле чараларны күрде. Әлеге факт буенча Комитет таныклыгы гамәлдән чыгарылды, предприятиедә хәләл продукция җитештерү туктатылды, «Челны мясо» компаниясе җитәкчелегенә кисәтү кәгазе җибәрелде.

Мин чын күңелдән әлеге фактларны ачыклауда ярдәм итүчеләргә рәхмәтемне белдерәм. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең хәләл стандартлары буенча Комитеты хәләл продукция җитештерүдә булган барлык җитешсезлекләрне ачыклау һәм тамырдан бетерү ягында, чөнки Комитет хезмәткәрләре кыямәт көнендә җавап тотачак. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте хәләл индустрия үсешенә өлеш кертүдә барлык тырышлыгын куячак, товар җитештерүчеләрнең ислам таләпләрен саклаулары өчен хезмәт күрсәтәчәк».

# Шәүвәл аенда уразаны каза кылу



**Сорау: Минем Рамазан аеның берничә көнен каза кыласым бар. Шулай ук шәүвәл аеның беренче атнасында ураза тоту да саваплы, дип ишеттем. Мин башта шәүвәл уразасын тотып, аннан Рамазан уразасын каза кыла аламмы?**

Җавап: Бу сорауга җавап бирер өчен, әүвәл бу уразаларның дәрәҗәсен билгеләп китик, бу сезгә нәрсәнең әһәмиятлерәк икәнен билгеләргә ярдәм итәчәк. Рамазан уразасы – фарыз ураза, ә шәүвәл аенык – мөстәхәб (киңәш ителә торган). Фарыз булган бар гамәлләрне дә үтәү яки каза кылу мөселман өчен мөһимрәк булып тора. Шул рәвешле, башта Рамазан уразасының калдырылган көннәрен каза кылу хәерлерәк. Шәүвәл аеның алты көн уразасына килгәндә, аларны айның беренче атнасында тоту шарты юк, бу уразаны айның уртасында да тотарга мөмкин. Ә Аллаһка яхшырак мәгълүм.

**Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# Хәрам булачак туйга барырга ярыймы?




**Сорау: Якын туганым мине туена чакыра, анда хәрам әйберләр дә булачак (миңа ул мәҗлес хакында сөйләде). Ул үпкәләмәсен дип, мин бу чакыруны кабул итә аламмы?**

Җавап: Хәрам (тыелган) гамәлләр кылыначак мәҗлесләргә (туй һ.б.) бару тыела. Хәнәфиләр арасында киң таралган һәм билгеле булган «Әл-Фәтәва Әл-Һиндия» китабында: «Әгәр кешене гөнаһ кылыначак урынга чакыралар икән (мисал өчен, исерткеч эчемлекләр булачак туй), аңа бу чакырыну кабул итү хәрам (тыела)», – диелгән.

**Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин**

# Хаҗ турында



### Сорау: Хаҗның телдәге һәм шәригатьтәге мәгънәсе нәрсәне аңлата?

Җавап: Телдә «хаҗ» – «бөеклеккә омтылу», шәригатьтә – махсус урынга махсус вакытта махсус гамәлләр белән зиярәт кылудыр.

### Сорау: Исламда хаҗның хөкеме нинди?

Җавап: Хаҗ – Ислам әркәннәренең берсе. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә әйткән: **«Көче җиткән кешеләргә Аллаһка гыйбадәт өчен хаҗ кылу – фарыз».**

«Әли Гыймран / Гыймран гаиләсе», 3:97

### Сорау: Кемгә хаҗ кылу вәҗиб?

Җавап: Азат, акыллы, балигълыкка ирешкән мөселманга сәфәре тәмамланганчы транспорт белән тәэмин итә алырлык һәм шул ук вакытта гаиләсенең яшәешенә җитәрлек малы булган бай кешегә фарыз була.

Хатын-кызны озатып баручы мәхрәме, ягъни әтисе, туган абыйсы яки ире булырга тиеш. Әгәр Мәккәгә бару юлы бер намаз вакыты кадәр яки аннан да артыграк вакытны алса, мәхрәм кирәк була.

### Сорау: Хаҗның фарызлары нинди?

Җавап: Хаҗның 3 фарызы бар:
1. Ихрам кию.
2. Гарәфәт тавында басып тору.
3. Тәваф кылу.

### Сорау: Хаҗның вәҗибләре нинди?

Җавап: Хаҗның вәҗибләре:
1. Корбан гаетенең таңы атканда Моздәлифә үзәнлегендә басып тору.
2. Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөгерү.
3. Таш ату.
4. Саубуллашу тәвафы.
5. Чәчне кыскарту яки бөтенләй кыру.
6. Кояш баеганчы Гарәфәт тавында басып тору.
7. Карин һәм мөтәмәттигъ өчен корбан чалу.
8. Мөфриднең тәртибе болай: баштан таш ата, аннан соң чәчен кыра яисә кисә. Карин вә мөтәмәттигънең тәртибе: баштан таш ата, аннары корбан чала, ахырдан чәчен кыра яисә кисә.
9. Зиярәт тәвафын корбан көннәренең берсендә үтәү.
10. Чәч кыру яисә кисү изге Әл-Хәрам территориясендә булырга тиеш.
11. Корбан көннәрендә хаҗ кылу.

### Сорау: Хаҗның сөннәтләре нинди?

Җавап: Хаҗның сөннәтләре түбәндәгеләр:
1. Карин һәм ерактан килүченең (мөфрид) килеп җиту тәвафы (тәваф кудум).
2. Тәваф өчен ихрам кигәннән соң, Сафа һәм Мәрва таулары арасында йөгерергә ниятләү.
3. Зөлхиҗҗәнең 8 нче көнендә Минага барып куну.
4. Гарәфә көнендә (зөлхиҗҗәнең 9 нчы көне) кояш чыкканнан соң Минадан Гарәфәт тавына чыгу.
5. Корбан чалу көнендә Моздалифәдә куну.
6. Гарәфәт тавында госел алу.
7. Корбан чалуның калган көннәрендә Минада куну.

### Сорау: Хаҗда яки гомрәдә кагыйдә бозуның нинди төрләре булырга мөмкин?

Җавап: Ике төрле кагыйдә бозу бар:
1. Ихрамның тыелуларын бозу;
2. Хаҗ вә гомрә гамәлләрен бозу: вәҗибларын калдыру, тәртипләрен үзгәртү яисә фарызларын вә вәҗибларын вакытында үтәмәү.

Беренче төргә 8 төрле бозу керә:
1.Ирләргә тегелгән кием кию;
2. Ирләргә башларын каплау;
3. Ирләргә дә, хатын-кызларга да битләрен каплау;
4. Тәнгә, киемгә һәм урын-җиргә ислемай сөртү;
5. Чәчне кыру яки кыскарту;
6. Тырнакларны кисү;
7. Коры җир хайваннарына ауга чыгу һәм бу эштә катнашу;
8. Якынлык кылу, дәртләнеп үбү вә назлау.

**«Әт-тәсһил әз-зарури ли мәсәил Әл-Кудури» китабыннан**

# Татарстан мөфтие Казан FIFA матбугат үзәгендә журналистлар белән очрашты

19 июнь Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин 2018 елның футбол буенча FIFA дөнья Чемпионатының Казан шәһәрендә урнашкан матбугат үзәгендә булды. Матбугат конференциясе кысаларында Камил хәзрәт чит ил, федераль һәм республика масскакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре белән очрашты. Брифинг модераторы буларак танылган Казан тележурналисты Тимур Бикмурзин чыгыш ясады.



Аралашу барышында Татарстан мөселманнары башлыгы катнашучыларга республиканың ислам рухи потенциалы, Россиядә иң зур Диния нәзарәте булган республика мөфтияте эшчәнлегенең юнәлешләре, регионда күп төрле мәдәни традицияләр һәм өммәтнең бай дини тормышы турында сөйләде.

Аерым алганда, Татарстан мөфтие Чемпионат кунакларына һәм ярышларда катнашучыларга безнең җәмгыятьтә милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне кору тәҗрибәсен күрсәтү мөмкинлеге туу шатлыгы белән уртаклашты. Хәләлиндустрия турында бирелгән сорауга: «Без бу вакыйгага 30 ел әзерлек алып бардык», – дип шаяртты Камил хәзрәт җавабында. «Казанда хәләл кунакханәләр һәм хәләл стандартлары буенча эшли торган җәмәгать туклануы нокталары бик күп. Безнең мәчетләребездә ишекләр һәркемгә дә ачык».

– Казан хаклы рәвештә ислам дөньясының төньяк башкаласы статусына ия, – дип билгеләп үтте Камил хәзрәт. – Татарстанда иң дәрәҗәле ислам белеме бирү үзәкләре эшли һәм Россиядәге барлык мәчетләрнең чиреге Татарстанда халыкка хезмәт күрсәтә. Бирегә хәзерге татарларның борынгы бабалары – болгарлар Ислам динен дәүләт дине буларак 922 елда кабул иткән. Бу татар халкы язмышында гына түгел, ә Евразия кыйтгасының тарихында да җитди рәвештә тәэсир ясаган төп вакыйгаларның берсе. Шунысы игътибарга лаек, Россиядә ислам дине Русьне чукындыруга кадәр күпкә алданрак кабул ителүе мәгълүм.

Татар дин гыйлеме мәктәбе Россиядә генә түгел, бөтен ислам дөньясында да иң борынгы һәм иң дәрәҗәлеләрдән санала. Нәкъ менә татар ислам дине галимнәренең бәһасез хезмәтләрендәге дустанә мөнәсәбәтләргә һәм сабырлыкка өйрәтә торган Ислам нигезләре хакындагы мәгълүматлар бүгенге Россия өммәте һәм дөнья җәмгыяте өчен дә мөһим.

Регионда күп төрле мәдәни традицияләр һәм дустанә мөнәсәбәтләр темасын хәбәрчеләр дәвам итте. Аларның сорауларына җавап рәвешендә Камил хәзрәт владыка Феофан белән булган шәхси дустанә мөнәсәбәтләре турында әйтеп узды. «Безнең арада килешү бар – без мөнәсәбәтләрне бозуга китерә торган бәхәсле темаларга кагылмыйбыз. Безне берләштерә һәм уртак карарлар кабул итүне таләп иткән сораулар байтак: социаль әһәмияткә ия, рухи-әхлакый, яшь буынны тәрбияләү һәм башка мөһим бурычлар бар», – диде ул.

Матбугат конференциясе дөньяда төп футбол вакыйгалары кысаларында оештырылу сәбәпле, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен мөфтинең спортка карата фикере дә кызыксындырды. Билгеле булганча, Камил хәзрәт джиуджитсу белән мавыга һәм көрән билбау иясе булып тора. Ул журналистлар белән Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең мөселманнарны спортка һәм сәламәт яшәү рәвешенә җәлеп итү өлкәсендә алып барылган эшчәнлеге турында уртаклашты. Әйтик, Татарстан Республикасының барлык имамнары киләсе айда ГТО нормаларын тапшыру өчен җыелачагын әйтеп узды. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) әйтүенчә: «Көчле иманлы Аллаһы Тәгалә каршында көчсез иманлыга караганда яхшырактыр», – дигән хәдисне китерде. Шул ук вакытта ул хәбәрчеләргә футболны карап утырудан бигрәк күбрәк аны уйнарга яратуын, бигрәк тә ялгыз шөгыльләнә торган, кешенең чыдамлылыгын, тырышлыгын, ныклыгын сыный торган спорт төрләрен хуп күрүен белдерде.

Матбугат конференциясендә яңгыраган барлык сораулар арасында журналистларны агымдагы елның апрелендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә бирелгән Берләшкән Милләтләр Оешмасынының икътисади һәм социаль советы каршындагы консультатив статусы да кызыксындырды.

– Россиядә мондый статуска беренче һәм бердәнбер хөкүмәтнеке булмаган дини оешма – ТР мөселманнары Диния нәзарәте ия булды, – дип аңлатты Камил хәзрәт. – Әлеге статус, һичшиксез, Татарстан Республикасында мәдәниятара, конфессияара, милләтара тотрыклы мөнәсәбәтләрне тәэмин итүдә башкарылган сәяси хезмәтнең югары бәясе булып тора һәм Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Исламның традицион кыйммәтләрен ныгыту өлкәсендә алып барган эшчәнлеге нәтиҗәсенең халыкара дәрәҗәдә танылуын аңлата.

## «Мозаффария» кызлар өчен татар мөселман мәктәбе

Казанда кызлар өчен «Мозаффария» мәктәбе проектын тормышка ашыру өчен акча җыю игълан ителә.

Ә сине милләтебез киләчәге борчыймы?

«Мозаффария» мәктәбе бинасын төзекләндерүгә син дә үз өлешеңне керт!



### Ничек ярдәм итәргә?

1. 3116 номерына kazan сүзе белән ярдәм күрсәтү суммасын язып смс юлларга.

Мисал өчен: kazan 500

2. «Зәкят» хәйрия фондына акча күчерергә:

Банк ВТБ (ПАО) в г. Нижнем Новгороде
БФ «Закят» 16550688682
БИК 042202837
КОРР. СЧЕТ 30101810200000000837
КОД ОКПО 50330799
ИНН 7702070139
КПП 526002001
ОГРН 1027739609391
Расчетный счет 40703810525240000135.

3. halalstarter.com сайты аша проектка акча күчерергә.

# Мәдрәсәләр солтаны – «Мөхәммәдия»



Казан шәһәрендәге мәдрәсәләр солтаны булган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә 1882 елда бай татар сәүдәгәре Мөхәммәтҗан Галиев тарафыннан нигез салына. Ул бер катлы итеп таш бина төзеткән була, һәм бу мәдрәсә төзүчесе истәлегенә «Мөхәммәдия» исеме белән атап йөртелә башлый.

Бинаның баштагы мәйданы 16х8 метр була. Әмма шәкертләр саны күбәеп, сыймый башлагач, Мөхәммәтҗан аска тагын бер кат казытып тәрәзәләр куя һәм өскә дә бер кат өстәп, шул бинаны өч катлы итеп ясый. Мәдрәсәнең үз ашханәсе, хастаханәсе, аяк киеме төзәтү остаханәләре, китапханәләре булдырыла. Шәкертләр саны һаман арта торган, чөнки уку-укыту, тәрбия эше җайга салынып эшләгән мәдрәсә турындагы хәбәр бөтен Россия мөселманнары арасында тарала. Бирегә инде татар яшьләре генә түгел, ә башка төрки халык вәкилләре дә гыйлем алырга килә башлаганнар, һәм тагын да шәкертләр сыймау сәбәпле яңа бина төзү кирәк була. Артыннан бик озак йөргәннән соң, 1901 елда 3 катлы таш бина салына. Бу бина инде үзәктән ягып җылытыла торган булып, шәкертләр өчен мөмкин булган бөтен уңайлыклары булдырыла.

Аталы-уллы Галиевлар тырышлыгы белән барлыкка килгән бу мәдрәсәнең матди нигезен булдыручы өлкән Галиев Мөхәммәтҗан булса, аның улы Галимҗан Галиев-Баруди – мәдрәсәнең рухи кыйммәтен барлыкка китерүче. Һәм соңгысы мәдрәсәнең ачылу көненнән алып Совет хакимияте тарафыннан ябылганчыга кадәр бу уку йортының алыштыргысыз җитәкчесе була. Кызганыч, 1918 елда мәдрәсәне ябалар. Шушы 36 ел эшләү дәверендә «Мөхәммәдия» меңләгән шәкерткә белем иңдергән, югары квалификацияле белгечләр әзерләгән. Алар арасында – Хөсәен Ямашев, Мәхмүт Дулат-Али, Камил Якуб, Касыйм Туйбактин, С. Габбасов кебек ялкынлы революционерлар, Миргазиз Укмасый, Зариф Бәшири, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Фатих Әмирхан, Әнәс Камал, Кәрим Тинчурин, Гыйбад Нугайбәк, Галимҗан Шәрәф, Хуҗа Бәдигый, Фәхри Әсгать, Фазыл Туйкин, Фәтхи Бурнаш, Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Исхак, Гали Рәхим, Г. Газиз, Габдрахман Мостафин һ.б. күренекле әдипләр һәм галимнәр, Борһан Шәрәф, Әхмәтгәрәй Хәсәни кебек журналист һәм нәширләр, Каюм Насыйри кебек энциклопедист галим һәм әдипләр, Закир Шакиров кебек мәгърифәтче-педагоглар, Мәхмүт Алмаев кебек революционер, шагыйрь, полиграфия белгечләре, Х. Биккенин, И. Әмирхан кебек күренекле дипломатлар, Сәед Вахиди кебек археограф һәм педагоглар, Зәйни Солтанов, Габдрахман һәм Габдулла Камал кебек талантлы артистлар, композиторлар Салих Сәйдәшев, Солтан Габәши, скульптор Бакый Урманче һ.б. бик күп мәшһүр шәхесләр.

«Мөхәммәдия»нең педагогик коллективы да зур булган. Төрле елларда мәдрәсәдә Г. Габидуллин Әл-Кырлави (юриспруденция), Т. Габделхәкимов Әл-Мәчкәрәви (гарәп теле, фонетика, морфология, каллиграфия), Җ. Сиражетдинов (әхлак), Б. Гомәров Әл-Кулаткылы (логика), Шәһәр Шәрәф (философия, гарәп теле), Таһир Ильяс (гарәп теле, лексикография, математика), Габдрахман Галиев (гарәп теле), Хәсән Солтанов (рус теле, соңыннан ТАССР Мәгариф буенча халык комиссары) һ.б. эшләгән. Әлбәттә, Галимҗан Баруди үзе дә төрле фәннәрдән белем биргән.

Мәдрәсә идарәсе үз шәкертләре арасыннан иң сәләтлеләрен сайлап, аларга яшь шәрикләрен укыту хокукын да еш биргән. Мондыйлардан Закир Шакиров – тарих, география, Зәки Уразаев, Мирза Гозәеров, Әхәт Богданов – математика, Хуҗа Бәдигый – татар теле һәм әдәбияты, фольклоры (соңыннан КДПИ профессоры), Борһан Хәбиб – физика, химия, Нәҗип Зәетов физика укыталар. Гаять сәләтле Борһан Шәрәф 18 яшеннән үк мәдрәсәдә гарәп һәм фарсы телләреннән практик дәресләр алып бара. Г. Камал 1900-1904 елларда татар теле, Ф. Әмирхан 1904-1906 елларда география буенча дәресләр бирә.

Кайбер фәннәр программада каралмаган булса да, дәмолла Баруди инициативасы белән өстәмә рәвештә укытылалар. Доктор Әбүбәкер Терегулов – медицина, гигиена, адвокат Сәедгәрәй Алкин – хокук, Фатих Әмирхан төрле партияләр турында дәресләр бирә. 1905 елда Йосыф Акчура сәяси тарих укыта.

«Мәдрәсәи Мөхәммәдия»дә заманында рус-Европа гомуми белем бирү мәктәпләрендәге барлык дөньяви фәннәр дә диярлек укытылган, ә кайберләре югары уку йортларындагылар белән тәңгәл килгән. Мондый мәдрәсәләрдә, дип яза Казан уку-укыту округы Я. Д. Коблов 1916 елда, «шәкертләрнең фикри үсеш дәрәҗәсе шактый зур югарылыкка җитә». Ә 1911 елда инглиз журналы «The Moslim World», татар яңа методлы мәдрәсәләрнең уку программаларына анализ ясап, аларның классик гимназияләргә охшаганлыгын һәм биредә латин, грек телләре урынына гарәп һәм фарсы телләре укытылуын күрсәтеп китә.

1990 елда Татарстанның дәүләт суверенлыгы хакында Декларация кабул ителгәч тә, халкыбызның күпьяклы үсеше өчен мөмкинлекләр киңәя. Шуңа күрә идеологик киртәләр җимерелеп, дин иреге рөхсәт ителеп, үзгәртеп кору чоры башлангач ук, татар зыялылары арасында «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен кире кайтару-торгызу турында уйлана башлыйлар. 1993 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен ачу өчен җирлек булдырыла. Ләкин тарихи бинаны 1997 елның 24 нче июнендә генә тулысынча кире кайтару насыйп булганлыктан, моңарчы уку-укытулар баштан Ленин исемендәге мәдәният сараенда, яңа төзелеп ятучы «Рамазан» мәчете бинасында, «Нурислам» мәчетенең мәдрәсә бинасында һәм мөселман җәмгыяте куллануына кире кайтарылган «Апанай» мәчетендә алып барыла.

Хәзерге вакытта «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә бер меңнән артык шәкерт белем ала. Аларның килеп уку географиясе бик киң: Омск, Ерак Себер, Төмән, Екатеринбург, Пенза, Оренбург, Сембер, Самара, Киров, Түбән Новгород, Төньяк Казахстан, Чиләбе, Ханты-Мансийск, Сарытау, Волгоград, Чита, Томск, Владимир өлкәләреннән; Нижневартовск, Ижевск, Петропавловск, Петрозаводск шәһәрләреннән; якын күршеләребез булган Чувашстан, Башкортстан, Удмуртия, Мари Эл Җөмһүриятеннән; хәзерге вакытта БДБ илләре дип аталган – Таҗикстан, Казахстан, Үзбәкстан, Украина һәм Белоруссия җөмһүриятләреннән һәм дә инде Казаныбыздан һәм җөмһүриятебезнең башка шәһәрләреннән-мәхәлләләреннән җыелышып мәдрәсәбездә гыйлем алалар.

Программага кертелгән 39 фәннең 19ы дини фәннәр: Изге Коръән, әхлак һәм әдәп, гакыйдә (дөньяга ислам карашы), фикһ (ислам хокуклары), тәфсир (Коръән Кәримнең сүзгә-сүз мәгънәсе һәм гомуми аңлатмасы), хәдисләр, Коръән уку кагыйдәләре, сира (Пәйгамбәребез галәйһиссәләмнең тормыш юлы), күркәм язу (каллиграфия), исламда хатын-кыз урыны, Коръән Кәрим аятьләренең иңү тарихы һәм иңү сәбәпләре турындагы фән, Коръәндәге кыйссалар, ислам тарихы, шәригать тарихы, мирас, ысул фикһның нигезләнүе, дәгъват нигезләре, диннәр һәм секталар дигән фәннәр укытыла.

Дөньяви фәннәр 20: гарәп теле буенча гамәли дәресләр, гарәп теле грамматикасы, фонетика, татар теле һәм әдәбияты, Татарстан тарихы, ислам дәүләтләре, гарәп теленең сөйләм стиле, гарәп әдәбияты, тәрҗемә теориясе һәм практикасы, гарәпләрдә шигырь төзелеше, библиография, ислам фәннәрен укыту ысулы, хәзерге ислам дөньясы, Исламның алга китеше, педагогика нигезләре, методика, психология нигезләре, чит телләрне өйрәнү теориясе, инглиз теле, сөйләм стиле, матур сөйләм укытыла.

«Мөхәммәдия» мәдрәсәсенең максаты – дин эшлеклеләрен әзерләү белән генә чикләнеп калмыйча, югары мәдәниятле, әхлаклы, дини һәм дөньяви белемнәр белән коралланган, җәмгыятебезнең төрле тармакларында хезмәт итә алырлык белгечләр әзерләү.

■ **Язманы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе шәкерте Алия Мәссарова әзерләде**

# Сәүдә һәм гаделлек

Бүгенге көндә без һәрдаим сату-алу эшләрендә катнашабыз. Ә Ислам динендә сәүдә итүгә нинди таләпләр бар соң?

Көннәрдән бер көнне сөекле Пәйгамбәребез (аңа Аллаһының сәламе вә рәхмәте булсын) базарга бара. Бодай сатучы яныннан узып барганда, ул туктап, кулын бодай өеменә тыгып карый һәм бодайның аста бераз юеш булуын белеп ала. Кулын чыгарып ул сатучыдан: «Нәрсә бу?» – дип сорый. Бодай сатучы: «Йә Расүлуллаһ! Күптән түгел генә яңгыр явып китте, шуңа күрә бодай бераз юешләнде», – дип җавап бирә. Аллаһның илчесе: «Алай булгач, кешеләр күрсен өчен, юешләнгән өлешен өстә калдырырга иде», – дип таләп итә. Алга таба: «Безне алдаучы кеше бездән түгел», – дип өстәп куя.

Ислам дине кеше яшәешенең һәр тармагын колачлый. Әлеге хәдис безгә нәрсә хакында сөйли? Мөселманнар бервакытта да кешеләрне алдаган, үзләренең бер мизгеллек дөньяви файдалары өчен башкаларны ялгыш юлга этәргән кешеләр белән бергә булмаслар. Һичшиксез, Ислам дине сәүдә белән шөгыльләнүне хуплый. Расүлуллаһның әйтүе буенча, тугры сүзле, ышанычлы һәм гадел сәүдәгәрләр пәйгамбәрләр, әүлияләр һәм изге гамәлле кешеләр белән бергә кубарылачаклар. Шуңа күрә сату-алу яисә башка табыш китерә торган эшчәнлек белән шөгыльләнгән кешеләр бик гадел һәм намуслы эш итәргә тиешләр. Әгәр дә сатыла торган әйбернең берәр кимчелеге булса, сатучы ул хакта сатып алучыны кисәтергә бурычлы.

Гыйбадәт кылганда үзеңне Аллаһы Тәгалә каршында басып торгандай хис итеп, ихсан белән кылырга кирәк булган кебек, сәүдә, бизнес һәм башка эш белән бәйле мөнәсәбәтләрдә дә Аллаһы Тәгалә безне һәрдаим күреп торуын истә тотарга кирәк.

Хәзрәти Гомәргә бер кешенең намуслы һәм гадел булуы хакында хәбәр итәләр. Гомәр радыйаллаһу ганһү: «Сез аның намуслылыгын һәм гаделлеген раслар өчен аның белән сәүдә мөнәсәбәтләрендә булдыгызмы?» – дип сорый. Аңлашылганча, кешенең әхлакый сыйфатлары һәм тәкъвалыгы сату-алу эшләрендә чагыла.

Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

**«Аллаһ күкне күтәрде һәм һәрнәрсәгә гаделлек белән үлчәү куйды. Гаделлектән, дөрес үлчәүдән читкә чыкмавыгыз өчен. Үлчәүләрне гаделлек белән торгызыгыз һәм үлчәүне киметмәгез, ягъни кешегә үлчәп биргәндә киметеп үлчәмәгез һәм үзегезгә алганда арттырып үлчәмәгез!»**

«Әр-Рахмән / Рәхимле», 55:7-9

Шулай ук:

**«Киметеп үлчәүчеләргә үкенечле каты газаптыр. Алар башка кешеләрдән берәр нәрсә үлчәп алсалар, үлчәүне тутырып, мул үлчәп алалар. Әгәр башка кешеләргә савыт яки бизмән белән үлчәп биргәндә, киметеп үлчиләр».**

«Мутаффифин / Киметүчеләр», 83:1-3



Аллаһы Тәгалә сүрәнең беренче аятендә үк, җөмләнең беренче сүзе белән зур кисәтү ясый: «вәйлүл-лил мутаффифин». «Вәйлүн» сүзе «үкенечле каты газап» дип тәрҗемә ителә. Ни өчен? Чөнки алар алдаганнарын белә торып, бу эшкә баралар. Ә бит Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Безне алдаучы кеше бездән түгел», – дип әйтте.

Бу аятьне тәфсир кылучылар болай дип әйтте: «Мондый тәр кешеләр үзләренә ни дә булса алырга җыенсалар, алар аласы әйберне тулысы белән, киметмичә алалар. Ә калган кешеләргә бу товарларны саткан вакытта, алар ул товарны бераз киметеп үлчиләр (килограммлы әйберләрне үлчәүдә киметеп, тукыма ише әйберләрне метрын азайтып саталар). Бу кешеләрнең милекләрен урлау һәм аларның хакларына керү була. Әгәр дә бу сәүдәдә алдаганнар үзләре өчен генә шундый куркыныч кисәтү дип уйласалар, дөреслектә, бу аять өстендә кешеләрнең милекләрен көч белән урлаучыларга, каракларга бик нык уйланырга кирәк.

Бу аятьләрдән, хәдисләрдән сәүдә эшенең ни кадәр җаваплы хезмәт икәнен аңлап була. Сәүдә эшенә керешкән һәрбер кеше, иң башта үзенең ниятен билгеләргә тиеш. Сату-алу эшендә күңелендәге изге нияте кешене гөнаһлы юлга кереп китүдән, ин шә Аллаһ, саклап калыр. Гаиләсенең матди хәлен яхшыртам дип, сәүдә яисә башка төрле гамәл белән шөгыльләнүченең нияте дә, максаты да изге, күркәм булырга тиеш. Имам Бохари һәм Мөслимнең хәдис җыентыкларында килгән хәдистә: «Дөреслектә, гамәлләр ниятка карап бәяләнәләр», – дип әйтелә. Ягъни кеше көндәлек эшләрен дә гыйбадәткә әйләндерә ала: йокы, ашау-эчү, гаиләндә берберенә яхшы мөгамәләдә булу һ.б. Сәүдә итү дә шулай ук гыйбадәткә кайтып кала, бу Аллаһы Тәгалә бер төркем мөселманнарга кушкан фарыз кифая, чөнки бөтен кеше дә сәүдәне ташласа, кешеләр ачтан үлерләр иде. Шулай ук сәүдә белән шөгыльләнүчеләрнең нияте хәерче булып, хәер сорап йөрмәү була ала. «Кем дә кем үзенә бер хәер сорау ишеген ачса, Аллаһ аңа 70 хәерчелек ишеген ачар».

Сәүдә белән шөгыльләнгән һәр мөселман кешесе бу гамәлне үз гаиләсен, әти-әнисен тәэмин итеп тору өчен, шулай ук күршеләренә, туганнарына ярдәм итү йөзеннән башкарырга тиеш.

Бервакыт иртә белән, Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) һәм аның сәхабәләре утырып торган вакытта, таза гәүдәле бер яшь егетнең үз эше белән чабып йөргәнен күрделәр. Кайберләре шунда: «Бу үзенең көчен Ислам дине өчен тотса, хәерлерәк булыр иде бит», – дип әйттеләр. Шулвакыт Пәйгамбәребез (аңа Аллаһының сәламе вә рәхмәте булсын): «Алай дип әйтмәгез. Әгәр ул үзен хәер сораудан азат итәр өчен тырыша икән, ул Аллаһы Тәгалә юлында. Һәм әгәр дә ул үзенең хәлсез әти-әнисен тәэмин итү өчен чабып йөри икән, ул Аллаһы Тәгалә юлында. Үзенең гаиләсен туендырыр өчен, дип чабып йөрсә дә, ул Аллаһы Тәгалә юлында. Әмма калганнардан байрак булыр өчен, йә үзенең тәкәбберлеге аркасында чабып йөрсә, ул шайтан юлында», – дип әйткән.

Аллаһы Тәгалә дә сәүдә эшләрендәге гаделлек турында Коръән Кәримдә болай дип әйтә:

**«Ий мөэминнәр! Көтәргә вакытын билгеләп бурычка мал бирсәгез, малны һәм вакытны языгыз! Бу эшләрне арагызда бер язучы гаделлек белән язсын! Яза белгән кеше язудан баш тартмасын, Аллаһ аңа язуны өйрәткәне өчен шөкер итеп язсын! Бурычка алып торучы да күпме алганлыгын һәм кайчан бирәчәген дөрес әйтеп яздырсын һәм хыянәт итәргә тәрбиячесе булган Аллаһтан курыксын, үзенең бурычларыннан һәрнәрсәне киметеп әйтмәсен.**

«Әл-Бәкара / Сыер», 2:282

Күргәнебезчә, сәүдә эшеме ул, түгелме, һәрбер эштә Аллаһы Тәгалә гадел булырга куша. Бурычка алучы кеше үзенең кайчан бирәчәген әйтергә, алай гына да түгел, аны язма рәвештә күрсәтергә тиеш. Кызганычка, бүгенге көндә без берберебездән: «Бернichә көнгә генә бер-ике мең сум биреп тор әле», – дип, әҗәткә кереп, акча алып торырга гадәтләндек. Әмма бу гамәлләр барысы да сүздә генә кала, ягъни, бүгенге көн сүзе белән әйткәндә, расписка яздырылмый. Әлбәттә, 100 мең турында сүз барганда, без тизрәк кәгазьгә ябышабыз. Әмма аз суммадагы килешүләр дә шулай ук язмача төзелсә, шәригатебезгә муафыйк гамәл булачак.

Шул рәвешле, гыйбадәттә күркәм әхлаклы, ихлас һәм тәкъва булырга тырышкан кебек, кешеләр белән мөнәсәбәттә, шул исәптән сәүдә эшләрендә дә, без шундый булырга тиешбез. Сату-алу эшләре белән шөгыльләнгән кеше беренче чиратта гаделлек һәм намуслылык нигезләренә таянырга тиеш. Пәйгамбәребезнең хәдисе безгә шул хакта сөйли.

■ «Шура» №21

# «... Кем дә кем нурларын арттыра ала, шуның өстендә эшләсен»

Тәһарәт – мөселман кешесенең көн саен кыла торган гыйбадәтләренең берсе. Аллаһы Тәгалә бар әйбердә дә чисталыкны ярата һәм мөселманнар өчен дә чисталыкны фарыз итеп кылды. Мөселман кешесенә аның уй-фикерләре һәм ниятләре, сөйләме, гамәлләре һәм, әлбәттә, аның тәне чиста булуы бик мөһим. Хәдисләрдә әйтелгәнчә, күңел һәм тән чисталыгы арасында элемтә бар. Шуңа күрә, рухи яктан үсешебез алга таба барсын өчен, үзебезнең тәһарәтебезгә аерым игътибар бирергә кирәк.

Һәрвакыт тәһарәтле йөрү авыр, әмма аның фазыйләте зур. Бу гамәл авыр күренмәсен өчен, бу темага карата берничә хәдис әйтеп китәсе килә. Тәһарәт аркасында:

**1. Фәрештә Аллаһтан сезнең өчен истигъфар сорый**

«Тәнегезне юып, чистарынып торыгыз, шулвакыт Аллаһ сезне чистартыр. Дөреслектә, әгәр дә кол тәһарәтле килеш йокларга ятса, аның янына бер фәрештә төшә. Һәм ул һәр сәгать саен Аллаһка: «Йи, Аллаһ, бу колыңны ярлыка, дөреслектә, ул тәһарәтле килеш йоклап китте», – дип дога кыла» (Тәбәрани).

**2. Бөтен тән чистара**

«Әгәр дә бер кеше тәһарәтен «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» дип башласа һәм тәһарәт алу барышында Аллаһны зикер итсә, аның бөтен тәне чистара. Әгәр «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» дип әйтмәсә, тәһарәт алган урыннары гына чистара» (Әбү Һөрайра).

**3. Җәннәткә юл ачыла**

«Камил рәвештә тәһарәт алганнан соң, ике рәкәгать намаз укып, ихлас ният белән фарыз намазын укырга дип юнәлгән кешегә җәннәт фарыз булачак» (Имам Мөслим).

**4. Кеше гөнаһлардан арына**

«Әгәр кеше камил рәвештә тәһарәт алып, ике рәкәгать намаз укыса һәм бу вакытта аның күңеле дөньяви мәшәкатьләрдән арынып торса, аның барлык гөнаһлары да гафу ителәчәк һәм ул яңа туган сабыйга охшап калачак».

**5. Кыямәт көнендә мөселманнарның йөзләреннән нур бөркеләчәк**

Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Кыямәт көнендә минем өммәтем тәһарәт алган урыннарыннан, ягъни йөзләреннән, кулларыннан һәм аякларыннан нур бөркелгән килеш чакырылачак. Кем дә кем нурларын арттыра ала, шуның өстендә эшләсен» (Имам Бохари).

**6. Иман камилләшә**

Пәйгамбәребез Мөхәммәд: «Гадел булырга тырышыгыз, әмма сез һәрбер эшегездә дә камил була алмассыз. Сезнең иң яхшы гамәлегез – намаз. Һәм бары тик мөэмин мөселман гына һәрвакыт тәһарәтле йөри» (Ибне Мәҗәһ).

**7. Әҗер-савап арта**

«Әгәр дә кеше тәһарәтле булып, тагын тәһарәт алса, Аллаһы Тәгалә аңа 10 изге гамәл язып куя» (Тирмизи).

■ **Islam-today.ru**

# Кештәдә торган Коръәнне кулга алыр вакыт

Калган эшкә кар ява икәнен барыбыз да беләбыз, шуңа да карамастан, һәркемнең «соңрак эшләрмен әле» дигән эшләре җыелганнан җыела бара. Ул гына да түгел, без бу гадәтебезгә шулкадәр ияләшеп беттек, үзебез дә сизмәстән ул безнең дини тормышыбызга да үтеп керде. Кайсы гына гыйбадәтне алсак та, без еш кына аңа вакыт таба алмыйбыз, кичектерәбез, эшләрмен әле, дип бер читкә этәрәбез. Шул рәвешле Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән ерагая баруыбызны да сизми калабыз. Тәһәҗҗуд намазын укыр вакытта без йоклыйбыз, Коръән укырлык буш вакытыбыз булганда, аны телевизор, социаль челтәрләргә бетерәбез. Күрәбез ки, дини гамәлләребезгә шул рәвешле битараф карау, ялкаулык күрсәтү безнең өчен бик мөһим бер проблемага әйләнде. Без моның белән, үзебез дә аңламыйча, күп нәрсәне югалтабыз.

Шул рәвешле көн саен үти алырга көчебездән килгән, ләкин никтер һаман кулыбыз барып җитмәгән изге гамәлләрнең берсе – ул Коръән уку. Аллаһ Китабын укымас өчен без нинди генә сәбәп эзләп тапмыйбыз: вакыт җитми, аятьләрнең мәгънәсен аңламыйм, гарәп телен белмим, дигән булабыз.

Әйтәсем килгәне шул: Коръәнгә карата шундый мөнәсәбәттә булуыбыз – бик зур ялгыш. Аллаһы Сөбхәнә вә Тәгалә Коръәндә болай дип әйтә: **«Аллаһның илчесе әйтте: «Йә Рабым! Минем кавемем Коръәнне ташлады».**

«Фуркан / Аеручы», 25:30

Хәзер Пәйгамбәребезнең безнең хакта шул сүзләрне әйтүен күз алдыгызга китерегез. Әйтик, Расүлуллаһ Аллаһка безнең Коръән укуны ташлавыбызга зарлана, ди. Кыямәт көнендә Коръән безгә каршы шәһадәт бирәчәк, чөнки без иң күркәм сүзләргә – Аллаһ сүзләренә карата игътибарсыз булдык, Раббыбыз белән элемтәне өздек, Аның рәхмәтеннән һәм бәрәкәтеннән аерылдык. Югыйсә, Коръән – безнең өчен тормышыбызда иң мөһим җитәкче. Ә ул ташландык хәлдә, онытылган булып, тузанланып киштәдә ята.

Коръәнне ташлау ул әле аны укудан туктау гына түгел, бәлки тыңлаудан, ул кушканны үтәүдән, аятьләре хакында фикерләүдән, шуннан җанга шифа-дәва эзләүдән туктау.

Ә без ничек уйлыйбыз? Фарыз итеп куелмаган, димәк, үтәү мәҗбүри түгел, эшләмәсәк тә ярый, дибез. Көн саен Коръән укуга карата да безнең мөнәсәбәтебез шундый. Ләкин әгәр без Аллаһка якынаерга, иманыбызда нык торырга, җаннарыбызга тынычлык табарга телибез икән, безгә берничек тә шундый ваемсыз булырга ярамый.

Аллаһ Тәгалә Коръәндә болай ди:

**«Без мөэминнәрнең күңелләренә шифалы аятьләрне вә Коръәннән рәхмәтле хөкемнәрне индерәбез, әмма Коръән белән гамәл кылмаган залимнәргә Коръән аятьләре хәсрәтне вә һәлакәтне генә арттырыр».**

«Бәни Исраил», 17:82

Күз алдыгызга китерегез: сез Коръән Кәрим китабын ачкан саен, сезгә Аллаһның рәхмәте һәм бәрәкәте иңә башлый. Сезгә, гаиләгезгә һәм йортыгызга иңә ул бәрәкәт. Сез Коръәннән бер генә бит укысагыз да, Аллаһы Тәгалә сезнең барлык мәшәкатьләрегезне җиңел хәл итәчәк, җаныгызга тынычлык индерәчәк. Болар барысы да Коръәннең нинди зур көч икәне хакында сөйли.

Вакыт табалмыйм дисезме? Көненә 15 кенә минут бүлегез: шул да җитә! Аена ул җиде ярым сәгать булачак. Сез ай саен 7,5 сәгать Коръән укыган буласыз!

**Коръән укыр өчен аерым бер вакыт билгеләгез**

10-15 кенә минут булса да, иң мөһиме, даими булсын. Ләкин шул вакытны кичектерер өчен үзегезгә сәбәп эзләмәгез. Үз графигыгызга тугры калыгыз, Коръән укыр өчен аерган вакытыгызны фәкать Коръәнгә генә багышлагыз.

**Коръән укуны гадәткә кертегез**

Сез һәр иртә саен тешләрегезне чистартасыз, бу инде гадәткә кергән, теш чистартмыйча тора алмыйсыз. Коръән укуны да үзегезнең көндәлек гадәтегезгә әверелдерегез. Мәсәлән, көн саен 5 аять укуны максат итеп куйсагыз һәм шул максатыгызны үтәп барсагыз, тора-бара ул сезнең гадәтегезгә кереп китәчәк һәм сез, үзегез дә сизмәстән, Коръәнгә үреләчәксез.

**Коръән уку дәресләренә йөрегез**

Әлбәттә, бу киңәш сезнең белем дәрәҗәгезгә бәйле. Әгәр гарәп хәрефләрен белмәсәгез, тәҗвид һәм гарәп теле дәресләренә йөрергә мөмкин. Коръәнне аңлап укырга өйрәнергә теләсәгез, тәфсир дәресләренә барырга була. Тәфсирне белсәгез, хифз белән шөгыльләнегез, Коръәнне яттан өйрәнегез. Ничек кенә булмасын, югары гыйлемле остазлар сезгә Коръәнне даими укуда, һичшиксез, ярдәмгә киләчәкләр.

Коръән ул дәшми торган остаз кебек. Ул безнең акылыбызга һәм тормышыбызга юнәлеш бирә. Аны күбрәк укыган саен, нәтиҗәсе дә күбрәк булачак. Күбрәк укыган саен, Коръән сезгә үзенең серләрен ачачак, гыйлемегез артачак, белгән әйберләрегезне дә үзегез өчен яңа яктан ачачаксыз. Сезнең карашларыгыз, күзаллавыгыз үзгәрәчәк, җаныгыз тынычлык табачак, сорауларыгызга җавап алачаксыз. Һәм бу – Аллаһы Тәгаләнең чиксез рәхмәте, олуг нигъмәте...

■ **Islam-today.ru**

# Мөэминнәрнең әмире – Гомәр радыйаллаһу ганһү

### Гомәрнең Ислам динен кабул итүе

Гомәр бине Хаттаб Мөхәммәд галәйһиссәләмнән 13 яшькә кечерәк булып, якынча 584 елда туган. Билгеле булганча, Гомәр радыйаллаһу ганһү ислам динен беренче кабул итүчеләрдән булмый. Җаһилият вакытында ул ислам диненең дошманы була, аңардан бик күп зарар ирешә. Мөселманнар үзара: «Гомәр ислам динен кабул иткәнче, аның ишәге беренчерәк ислам динен кабул итәчәк», – дип сүз йөртәләр. Бары тик Мөхәммәд галәйһиссәләм генә аннан өметен өзми, бәлки шундый гайрәтле затның Исламга килеп, мөселманнар файдасына хезмәт итүен өмет итеп: «Йә Раббым! Исламны Гомәр белән өстен һәм куәтле ит», – дип дога кыла.

Гомәр апасы Фатыйманың ислам динен кабул иткәнен белгәч, йортына бәреп үк керә. Сәгыйтьне сугып ега, ирен якларга теләгән апасына да өлеш чыга. Канга буялып, җирдә яткан Фатыйманы һәм Сәгыйтьне күреп, кылган гамәлләре өчен бик нык үкенә һәм апасыннан: «Сез нәрсә укыдыгыз? Бир әле, мин дә укып карыйм», – дип сорый. Гомәр госел алып, апасы кулындагы төргәктән «Та Һа» сүрәсен укый. Шулчак ул: «Бу нинди гаҗәеп, матур сүзләр. Кешеләр бу сүзләрне әйткән кешедән кала беркемгә дә гыйбадәт кылырга тиеш түгелләр! Мине Мөхәммәд янына алып барыгыз!» – дип әйтә.

Гомәр Мөхәммәд галәйһиссәләмнең өенә юнәлә. Пәйгамбәребез каршысына килеп, шәһадәт кәлимәсен әйтә. Мөхәммәд галәйһиссәләм аңа шул вакытта «Фәрукъ» – «аеручы» исемен биргән. Ул аңа: «Син хаклыкны батылдан аера алдың», – дип әйткән. Гомәр хәбәр таратучыны чакырып, бөтен кешегә үзенең ислам динен кабул иткәнлеге хакында җиткерергә куша. Бу вакыйгадан соң мөселманнар Ислам динен ачыктан-ачык тота башлыйлар, курыкмыйча Кәгъбәтуллаһ янында намаз укыйлар. Шул рәвешле, Аллаһы Тәгалә ислам динен Гомәр белән куәтли.

### Гомәр радыйаллаһу ганһүнең тыйнаклыгы

Гомәр радыйаллаһу ганһү сәхабәләр арасында үзенең тыйнаклыгы белән аерылып тора. Бервакыт, хәлифә булган хәлендә мәчеткә килеп кергәч, җыелган барча халык аны аягүрә басып каршы алалар, юл бирәләр. Гомәр үзендә тәкәбберлек хисен сизә. Мөнбәргә баскач, ул көтү көткән вакытларында булган хәлләрен, көннәр буе ач йөргәнен сөйли. Халык гаҗәпләнеп: «Әй, Гомәр, үзеңне нигә кимсетәсең?» – дип сорыйлар. Гомәр аларга: «Мин сезнең каршыгызга килгәч үземдә тәкәбберлек сиздем һәм мин аңа үз урынын күрсәтергә теләдем», – дип җавап кайтара.

### Гомәр радыйаллаһу ганһүнең Аллаһы Тәгаләдән куркуы

Гомәр һәр гамәлен дә Мөхәммәд галәйһиссәләмнең «Кем шиккә төшә, хәрамга төшкән кебек булыр. Кем шиктән ерагая, ул үзенең динен һәм намусын саклап калган кебек булыр», дигән хәдисенә нигезләнеп башкара.

Бервакыт аңа сөт китерәләр. Ул сөтнең тәмлелегенә сокланып: «Бу тәмле сөтне кайдан алдыгыз?» – дип сорый. Ярдәмчеләре аңа бу сөтнең зәкәткә китерелгән дөяләрдән савып алынганлыгын әйтәләр. Гомәр үзенең зәкәт әһеле булмавыннан куркып, сөтне косып чыгарырга ашыга. Шул рәвешле ул үзен хәрамнан гына түгел, ә шикле нәрсәләрдән дә саклый.

### Гомәрнең игътибарлылыгы

Гомәр беренчеләрдән булып, кичен гади халык арасына чыгып, аларның хәлләрен белешеп йөри. Шулай беркөнне урамда йөргәндә еракта гына янган бер ут шәүләсен күреп ала һәм шул тарафка юнәлә. Ул якынрак килеп сәлам бирә, хәлләрен белешә. «Нәрсә пешерәсез, балаларың нигә елый?» – дип сорый ул хатыннан. Бу хатынның ире сугышта һәлак булган. Ризык җитмәгәнлектән балалары берничә көн буена инде ашамаганнар. «Балаларым мине аш пешерә дип уйласыннар һәм тынычлансыннар өчен, Казанда хәзер таш кайнатам», – дип әйтә хатын. Гомәр аннан сорый: «Сез нигә хәлифәгә бармыйсыз?» Теге хатын: «Без аны хәлифә итеп сайладык та, ул бездән ерагайды», – дип җавап бирә. Гомәр үзен акламакчы булып: «Ул сезне кайдан белсен соң?» – дип сорый. Хатын: «Без аны безгә якын булганы өчен сайладык. Ул хәлифә булды да, бездән ерагайды», – дип җавап кайтара. Гомәр башка үзен акларга сүз таба алмагач, тиз-тиз атлап китеп бара. Казнага барып, аннан бер капчык он, май алып чыга һәм теге хатынга алып бара. Үзе ризык әзерли. Тамаклары тук булгач, балалар да тынычлап йоклап китәләр. Соңыннан Гомәр радыйаллаһу ганһү читкә китеп, озак кына елап тора һәм үз-үзенә: «Әй, Гомәр, син шулай күпме кешенең башына җиттең, күпме баланы ачтан үтердең», – дип әйтә. Бу хәлләрдән соң Гомәр радыйаллаһу ганһү яңа туган балаларга 2 яшьләренә җиткәнче компенсация түләү хакында фәрман чыгара һәм ирләре сугышта вафат булган кешеләргә дә түләүләр бирелә башлый.

### Гомәр сүзләренең Коръән аятьләренә туры килүе

Мөхәммәд галәйһиссәләм аның турында әйтә торган булган: «Фәрештәләр Гомәрнең теле белән сөйли», чөнки Гомәр радыйаллаһу ганһү берәр мәсьәлә хакында әйтсә, шуны исбатлап Аллаһы Тәгалә Коръән аятьләрен иңдерә.

1) Бәдер сугышыннан соң әсирләр хакында киңәшләшкәч, Әбү Бәкер радыйаллаһу ганһү алар өчен мал алып, азат итәргә тәкъдим итә. Гомәр исә аның белән килешми, аларны кылыч аша үткәрергә дигән тәкъдим белән чыга. Мөхәммәд галәйһиссәләм Әбү Бәкернең сүзен хуплый. Озакламый Коръәннән аятьләр иңә:

**«Кулга төшкән әсирләрне мал алып азат итәргә пәйгамбәргә һич дөрес булмый, хәтта кәферләрне күп үтергәннәренә кадәр. Сез мөселманнар дөнья малын телисез, Аллаһ сезнең өчен ахирәтне тели, Аллаһ көчле вә хикмәт белән эш кылучы. Әгәр хаталык кылучылар гафу ителәләр дигән сүз Аллаһтан булмаса, әлбәттә, әсир өчен алган малыгыз өчен сезгә олуг газап ирешкән булыр иде».**

«Әнфәл / Табыш», 8:67-68

Бу аятьләрдә Гомәрнең сүзләрен исбатлау һәм әсирләр өчен мал алуның дөрес түгеллеге раслана.

2) Монафикъларның башлыгы Габдулла бине Гобәй вафат булгач, абыйлары Мөхәммәд галәйһиссәләм янына килеп, аннан җеназа намазы укуын сорыйлар. Пәйгамбәребез галәйһиссәләм Габдулла бине Гобәйне гафу итә һәм аңа җеназа намазы укый. Гомәр монафикъларга җеназа намазы укуы һич дөрес түгел дип каршы чыга. Озакламый аның сүзләрен куәтләп түбәндәге аять иңдерелә:

**«Әгәр алардан берсе үлсә, мәңге җеназа намазын укыма һәм каберенә дә барып басма, ягъни монафикълар мәетенең бер эшенә дә катнашма, чөнки алар каршылык күрсәтеп Аллаһка һәм Аның расүленә кәфер булдылар һәм тәүбә итмичә, фәсикъ хәлләрендә үлделәр».**

«Тәүбә», 9:84

### Шәһид булып китүе

Гомәр радыйаллаһу ганһү шәһид булып китәргә тели. Барлык сугышларда катнашып, гел алгы сафларда




була, үзен аямыйча көрәшә. Сугышлар тәмамланып, шәһид булып китмәгәч, кайгырып елый, «мин шәһид булып китәргә лаек түгелмендер», – дип уйлый.

Бер көнне Гомәр радыйаллаһу ганһү тәкбир әйтеп, намазга кереп киткәч, имам артына баскан Әбү Лөэлә Әл-Мәҗүси Әл-Фәриси сафтан чыгып, Гомәрнең аркасына хәнҗәр белән берничә тапкыр кадый. Үзенә хәнҗәр белән кадаучының мәҗүси икәнлеген белгәч ул: «Әлхәмдүлилләһ, мөселман кулыннан китмим», – дип әйткән. Ул 23 нче һиҗри елда (644 ел) сишәмбе көнне, җомәдәл-ахыр аеның 22 нче көнендә, 63 яшендә шәһид булып китә. Җеназа намазын аңа Сөхәйб бине Синан укый.

### Гомәрнең эшләп калдырган эшләре

Гомәр радыйаллаһу ганһү хәлифәлеге вакытында гади халык өчен файдалы булган тәртипләр, кагыйдәләр кертелә: беренче тапкыр ислам тарихы языла; ел исәбен һиҗри календарь белән исәпли башлый; хәмер эчүчеләргә 80 камчы суктыруны кертә; Рамазан аенда мәчеткә җыелып, тәравих намазы укыла башлый; Җомга көне ял көне буларак игълан ителә; ашлык ташу өчен беренче тапкыр кораблар кулланыла башлый; базарларда үлчәү тигез булсын өчен герләр коеп ясала; почта хезмәте кертелә; халык исәбе алына һәм хәлифәлек губерналарга (өлкәләргә) бүленә; гаскәриләргә, ислам диненә хезмәт итүчеләргә, балалы хатыннарга түләүләр (компенсацияләр) бирелә башлый.

Гомәр радыйаллаһу ганһүнең гайрәте, Исламга булган хезмәте, залимнәргә һәм дин дошманнарына карата каты куллы булуы, тугрылык өчен бөтен дөньяны корбан итү дәрәҗәсендәге ихласлыгы, гаделлеге һәм болардан тыш бик күп күркәм сыйфатлары киләчәк буыннарга мисал һәм үрнәк булып, Ислам тарихында калдылар.

■ «Шура» №21

# Агачлар – планетабызның яшел үпкәләре

## Агачлар да Аллаһка сәҗдә кыла

Аллаһы Тәгалә кешелек дөньясын бик күп нигъмәтләр белән әйләндереп алган. Алар арасында агачлар да бар. Бу великаннар табигатьнең бер өлеше генә түгел икәнен аңларга кирәк, чөнки Аллаһы Тәгалә аларга Коръәндә аерым бер урын да билгеләгән. «Хаҗ» сүрәсенең 18 нче аятендә: **«Беләсеңме, дөреслектә, Аллаһка җирдә һәм күкләрдә булган мәхлуклар сәҗдә кылалар: кояш, ай, йолдызлар, таулар, агачлар, хайваннар, һәм күп кешеләр...»**, – дип әйтелә. Шулай итеп, Ул агачларны башка күркәм мәхлуклар белән берррәттән куя. Кеше үсемлекләргә, агачларга көнкүреш тормышында игътибар да бирми, чөнки алар игътибарны җәлеп итәрлек һәм аларга рәхмәт әйтерлек берниндидә эш башкармаган кебек.

## Агачлар – кислород чыганагы

«Иртәгәгә ышансаң, бүген агач утыртасың» дигән гыйбарәне барыгызның да ишеткәне бардыр. Шушы мәкаләне укый башлаганнан бирле ничә тапкыр сулыш алганыгызны исегезгә төшерә аласызмы? Ә безнең барлык тереклек өчен һаваның нинди зур әһәмияткә ия булганы турында еш уйланасызмы? Агач – табигатьнең бик мөһим элементы. Без сулый торган һаваның мөһим өлешен – кислород бүлеп чыгарып, гүзәл планетабызның яшәешен тәэмин итәләр алар. Шуңа күрә дә агачларны планетабызның «яшел үпкәләре» дип атыйлар. Тәмәке, кальян ише әйберләр үпкәләребезгә зарар китергән сыман, һаваның пычрануы да урманнарга начар тәэсир итә. Шуңа өстәп, урманнарны һәрвакыт кисеп торалар, бу да аларның мәйданы һәрвакыт кимеп тора дигәнне аңлата. Аллаһы Тәгалә кешене бу җиргә хәлифә итте. Бу турында «Бәкарә» сүрәсеннән укып белеп була. Ягъни кеше Җир шарында үзенә күрә бер җитәкче. Ә җитәкче үзенең хезмәткәрләре турында һәрвакыт кайгыртып торырга тиеш. Җир – Аллаһы Тәгаләнең мәхлугы. Аны саклау, аның турында кайгырту безнең бурычыбыз булып тора. Моңа Пәйгамбәребез галәйһиссәләм сөннәте дә, Аллаһның китабы Коръән дә ишарә итә.

## Коръәндә агачлар турында

Коръәндә пальма, зәйтүн һ.б. агачлар да искә алына. Шулай ук аларны Аллаһы Тәгалә күркәм сөйләм белән чагыштырып, болай ди: **«Беләсеңме «Лә иләәһә илләллаһ» сүзенә Аллаһ нинди гаҗәп мисал китерә, ул сүз яхшы үскән агач кеби, аның тамырлары җирдә мәхкәм, ботаклары күккә үрелгән, Раббысының әмере белән җимешне һәрвакыт биреп торыр».**

«Ибраһим», 14:24



Бу аять белән Аллаһы Тәгалә тәүхид кәлимәсен дә еш кабатларга өнди, чөнки дөньяда иң күркәм гыйбарәләрнең берсе – ул иман кәлимәсе.

Әбү Һөрайра радыйаллаһу ганһү мондый хәдис тапшыра: Пәйгамбәр Мөхәммәд галәйһиссәләм: «Мөэмин (мөселман) үсемлеккә тиң, аңа һәрвакыт җил исеп, авырлык тудырып тора. (Шуның кебек) мөэмингә дә һәрвакыт сынаулар килеп тора. Икейөзле кеше исә эрбет агачына охшаган. (Кисәр алдыннан гына тибрәлә башлый)», – дип әйткән.

«Әл-Мөэминүн» сүрәсенең 20 аятендә Аллаһы Тәгалә агачларның файдалары турында исебезгә төшерә: **«Дәхи Синай тавында үсә торган зәйтүн агачын кылдык, ул агач ашаучылар өчен май һәм ризыкның төсен үзгәртә торган буяу чыгарадыр».** Бүгенге көндә дә иң файдалы майларның берсе булып зәйтүн санала. Ә ашарга яраклы буяуларның күбесе Ислам шәригатенә каршы килә торган юллар белән ясала. Шуңа күрә Аллаһы Тәгалә Үзе күрсәткән юлларны сайларга кирәк. Пәйгамбәребез бу агач турында түбәндәгеләрне әйтеп калдыра: «Ашаганда зәйтүн маен кулланыгыз. Аны үзегезгә дә (тәнгә, чәчләргә) сөртегез. Дөреслектә, ул мөбарәк агачтан ясала (Ибне Мәҗәһ хәдисләр җыентыгыннан).

Шулай ук икенче бер аятьтә Хөдәйбия килешүе узган җирлек турында сүз бара. Ул килешү бер агач астында була, Пәйгамбәр бу килешүне мөшрикләрнең хыянәтләреннән соң төзи. **«Сугыштан кайтмыйча, Хөдәйбиядә агач төбендә сиңа ант бирүче сәхабәләрдән Аллаһ, шиксез, разый булды. Аллаһ аларның күңелләрендәге яхшы ниятләрен белде, аларга күңел тынычлыгын бирде, аларны якын җиңү белән шатландырды».**

«Фәтех / Җиңү», 48:18

## Пәйгамбәребезнең бүкәне

Мөхәммәд пәйгамбәр үзенең сәхабәләренә вәгазь сөйләгәндә пальма бүкәненә баса иде. Әмма соңрак аңа махсус минбәр ясадылар һәм икенче җомгага вәгазьне сөйләр өчен ул минбәргә менгәч, теге бүкән сабый бала елаган кебек сыкрап елый башлады. Шуннан соң Пәйгамбәр аның янына төшеп, кочаклап алды. Шулвакыт бу бүкән елавыннан туктый алмаган сабый кебек авыр итеп сулыйсулый елавын дәвам итте. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм: «Ул калган атналарны тыңлаган Аллаһны зекер итү сүзләрен сагынып елады», – дип әйткән. Икенче риваятьтә пальма агачына сөялеп сөйли иде, дип әйтелә.

## Агачлар җәннәт ачкычы

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләм: «Әгәр дә берәр мөселман агач утыртса яисә берәр нәрсә чәчсә, ә аннан соң берәр кош, кеше яисә хайван шул чәчкән, утырткан әйбернең уңышын ашаса, бу аңа, һичшиксез, сәдака булып языла», – дип әйткән (Имамнар Бохари һәм Мөслим хәдисләр җыентыгыннан). Пәйгамбәребез безгә күбрәк агачлар утыртырга, иген-кырларында чәчү эшләре алып барырга куша, ә без урманнарны кисәбез, юкка чыгарабыз. Ә бит Пәйгамбәрнең: «Пальмаларны кисмәгез, яндырмагыз. Җимеш китерә торган агачларны бетермәгез», – дип әйткәнен дә исебездән чыгармаска тиешбез. Әгәр дә үзебезнең бу эшләребезгә бераз гына игътибарлы булсак, табигатьне саклауга без дә өлеш керткән булыр идек. Көчле җилдавыллардан соң кайчакларда агачлар егыла, әмма аларны җыештырганнан соң, кызганычка, бүтән көннәрне яшь агачлар утырту өчен өмәләр ясалмый.

## Җәннәттәге агачлар

Җәннәт тормышы да агачлардан башка булмаячак, чөнки җәннәт агачлары турында бик күп хәдисләрдә әйтелә. Мөхәммәд Мостафа галәйһиссәләм: «Туба – җәннәттәге агач. Ул 100 ел озынлыгындагы юл кебек олыдыр. Вә аннан җәннәт әһелләренә киемнәр дә чыга», – дип әйткән. Бу дөньяда да шулай ук бит: безнең киемнәр җитеннән, мамыктан тегелгәннәр. Хәзер генә күп киемнәр синтетик юл белән ясалалар.

Шулай ук җәннәттә агачлар бүләк буларак та кулланылалар. Җәбир түбәндәге хәдисне китерә: «Пәйгамбәребез галәйһиссәләм: «Кем дә кем «Сөбхәналлаһи вә бихәмдиһ», ягъни Аллаһ барча кимчелекләрдән пакь һәм Аңа мактау булсын», – дип әйтсә, шул кешегә җәннәттә бер пальма агачы утыртылачак», – дип әйтте».

## Җәһәннәмдәге заккум агачы

Җәһәннәмнең дә үз агачы бар. Ул – заккум. Аның турында Аллаһы Тәгалә Коръән Кәримдә болай дип әйтә: «Кеше өчен мәңге торачак урын йөзеннән, нигъмәтләр белән тулган җәннәтләр яхшымы? Яки заккум агачы үсә торган җәһәннәм яхшымы? Ул заккум агачының җәһәннәм уты эчендә үскәнлегенә һәм җимеш биргәнлегенә ышанмыйлар, ышанмаулары аларга газап өстенә газап булачак. Ул җимеш энәле булып ашаганда тамакны ертыр, ачылыгы тамакны көйдерер. Ышанмаучыларга шул җимешне ашатырлар. **«Дөреслектә ул агач җәһәннәмнең төбеннән чыгып үсәдер».**

«Саффат / Сафта Торучылар», 37:62-65

Табигатьне саклау – һәркемнең бурычы!

Бу дөнья һәрьяклап ниндидер чикләүләргә корылган. Шуның кебек табигатьнең дә мөмкинлекләре билгеле күләмдә генә. Булмаганын сакламасак, ул күпмедер вакыттан соң, гомумән, юкка чыгуы бар. Аллаһы Тәгалә көчебездән килгәнче, һәрберебезгә дә бу изге эшкә өлешебезне кертергә насыйп әйләсә иде.

■ **Габделхәким Фәсхиев**

# Гайбәтнең зарары



Адәм балаларында бәдәни, ягъни тән белән бәйле булган авырулардан тыш, рухи хасталыклар да булырга мөмкин. Шушы җан белән бәйле булган чирләр кешенең үзенә һәм гомумән җәмгыятькә бик зур зыян китерә. Кальбебезне каралтып, гөнаһ сазлыгына батырып, кешенең дөнья вә ахыйрәт тормышына зарар сала торган шундый рухи чирләрнең берсе – ул гайбәт.

Ислам галимнәре гайбәтне тел афәтләреннән булган гөнаһлы гамәл дип билгелиләр. Шәригать буенча гайбәт ул – кемнең дә булса кимчелеген, нинди дә булса начар, тискәре сыйфатын шул кеше үзе янда булмаганда башкаларга сөйләү.

Кызганыч, әмма бик күп кеше гайбәтне зур гөнаһка санамый, янәсе, нәрсә булган соң, мин бит дөресен әйтәм, дип аклана. Әмма безнең Яратучыбыз Аллаһы Тәгалә бу гамәлне олы гөнаһлар, пычрак, җирәнгеч гамәлләр рәтенә кертә һәм изге Китабы Коръән-Кәримдә гайбәт сөйләүне мәет итен ашау белән чагыштыра (49:12).

Кеше кимчелекләрен барлап тел «чайкауны» кайбер галимнәр сасыган, бик начар исле үләксәне ашау белән дә тиңли. Димәк, без бер шикләнмичә-икеләнмичә гайбәтнең бик куркыныч, гөнаһлы һәм җирәнгеч гамәл булуын танырга тиешбез. Әмма... кем әйтмешли, тел тик тормый бит. Көн саен диярлек без берәр кешене (күршебезне, хезмәттәшебезне) начар яктан искә алып сөйлибез.

Сөйләгән сүзләребезнең гайбәт булуын каян белергә соң? Бик гади: әгәр син начар итеп искә ала торган кеше янда булмаса һәм син әйткән сүзләрне ишетеп ул үпкәләрлек булса, белеп торыгыз: бу – гайбәт, ә син – гайбәтче, ягъни сасыган үләксә итен ашаучы.

## Гайбәт сөйләүдән җан агулана

Мәгълүм булганча, бозылган ризык ашаудан тән агулана, гайбәт сөйләүдән исә җан агулана. Ислам галимнәре аңлатканча, гайбәт күңелне каралта һәм яман шеш тәнне үтергән кебек, кешенең иманын юк итә. Яман шешнең тәндә барлыгын күпләр соңарып белү сәбәпле һәлак була. Рухи хасталыклар исә иманга, җанга зур зыян салып, безне һәлак итәргә мөмкин. Шуңа күрә кеше рухи авыруларның яман нәтиҗәләре турында да, һичшиксез, хәбәрдар булырга тиеш. Гайбәт чире белән авырганыңны ничек белергә соң? Әгәр башкаларны начар яктан искә алудан күңелеңә ләззәт алсаң, әгәр гайбәт сөйләү рәхәтлек китерсә, белеп тор: синең кальбең авыру...

Шунысын да белү мөһимдер: кемдер турында гайбәт сөйләсәң, гамәл-гыйбадәт, изгелек кылудан сиңа язылган савапларны Кыямәт көнендә шул кешегә бирәсең була. Савапларың җитмәсә, тегә кешенең гөнаһлары синең гамәл дәфтәреңә күчәчәк. Хәсән Әл-Бәсри исемле галим үзе турында гайбәт сөйләгәнен белгәч, гайбәтчеләргә хат һәм бүләк җибәрә, хатында исә болай дип яза: «Минем хакта гайбәт сөйләгәнсез икән. Шулай булгач, савапларыгызның бер өлеше хәзер миңа бирелде, гөнаһларымның бер өлешен дә сез үз өстегезгә алдыгыз. Шуның өчен шушы бүләк-һәдиямне кабул итеп алуыгызны үтенәм».

Имам Шәрани дигән ислам галиме белдерүенчә, Кыямәт көнендә гамәл дәфтәрләрен кулына алган кайбер кешеләр әйтер: «Йә Раббым! Кайда соң минем укыган намазларым, тоткан уразаларым, биргән сәдакаларым? Нишләп аларның савапларын язылмыйча калган?» Аллаһы Тәгалә исә аларга: «Сез кылган изге эшләрегезнең барысы да гамәл дәфтәрләрегезгә язылып барды, ләкин сез аларны саклый алмадыгыз – гайбәт сөйләвегез аркасында савапларыгыз сез сөйләгән кешенең гамәл дәфтәренә күчерелде». Шулай итеп, гайбәт сөйләүнең нәтиҗәсе бик аяныч.

## Гайбәтне тыңлау да хәрам

Әле шунысын да белергә кирәк – гайбәт сөйләү генә түгел, аны тыңлау да хәрам. Мөхәммәд пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) бер хәдисендә болай дигән: «Гайбәт сөйләүче белән аны тыңлаучының гөнаһлары уртактыр».

Шундый катгый кисәтүләргә карамастан, кайберәүләр барыбер: «Мин дөресне сөйлим!» – дип кабат-кабат акланырга маташа. Пәйгамбәребез моңа да төгәл җавап бирә: «Кеше турында ул үзе ишетмәгәндә әйтелгән начар сүзләр дөрес, хак булса, бу – гайбәт, дөреслеккә туры килми икән, бу – бухтан (яла ягу)».

Әлеге хәрам кылынган гамәлнең куркыныч нәтиҗәсен аңлатып, Мөхәммәд гәләйһиссәләм бер мөбарәк хәдисендә болай ди: «Дөрестән дә, бик күп кеше тәмуг утына зина кылу һәм гайбәт аркасында эләгер. Ике аяк һәм ике ирен арасындагы әгъзаларыгызны гөнаһтан сакласагыз гына, сезгә җәннәт вәгъдә ителә ала». Пәйгамбәребезнең (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын): «Җәһәннәм әһелләренең күпчелеген хатын-кызлар тәшкил итәр һәм шуларның зур өлеше нәкъ менә гайбәт гөнаһын кылу сәбәпле тәмуг җәзасына дучар булыр», – дип әйтеп калдыруы да юкка түгелдер...

Көннәрдән бер көнне Мөхәммәд пәйгамбәр (аңа Аллаһның сәламе вә рәхмәте булсын) сәхабәләре белән мәчеттә утырганда, аларга әйтә: «Хәзер бирегә килеп керәчәк кеше – җәннәт әһеледер». Шуннан соң мәчеткә гади генә бер ир килеп керә. Соңыннан, инде мәчеттән чыккач, сәхабәләр аннан: «Җәннәткә кертердәй нинди гамәлең бар?» – дип сорыйлар. Бераз уйлап торганнан соң, ул болай дип җавап бирә: «Әллә ни зур гамәлләр кылганым юк, әмма шунысын гына әйтә алам: мин башкалар турында беркайчан да начар сөйләмим, алай гына да түгел – хәтта начар уйламыйм да».

Шулай итеп, телебезне «саклау» – мөселманнарга хас булырга тиешле сыйфатларның берседер. «Аллаһка ышанган кеше йә яхшы, файдалы сүзләр сөйләсен, йә бөтенләй дәшмәсен», – дип кисәтә безне пәйгамбәребез. Аллаһы Тәгалә исә Аңа тугры булган бәндәләрен өметләндереп, болай ди: «Кем дә кем башка кешенең гаебен белдертмәсә, ахирәттә аның гаепләрен белдертмәм». Шуңа да уйланыйк, сакланыйк һәм шайтан вәсвәсәләренә бирешмичә, Аллаһ вәгъдә иткәннәрне өмет итеп, пакь, саф күңел, чиста тел, ихлас иман белән, башкаларны хөрмәтләп, матур итеп яшик, җәмәгать.

■ **Ришат хәзрәт Курамшин,**
**Кукмара мәдрәсәсе мөдире**

# Дару үләннәрен җыярга соңга калмыйк!

Күп кенә авылларда, шулай ук, үз бакчалары булган кешеләр дару үләннәрен җыярга, киптерергә яраталар. Кемдер кышларын тәмле итеп үлән чәе эчәргә ярата, кемдер ул үләннәрне тән һәм чәчләр өчен профилактик чара буларак куллана. Кемдер аларны төрле авырулардан ничек кулланасын белеп, шуның өчен җыя. Максатлар төрле була ала, әмма һәрбер үлән җыючы кеше, аларны кайчан җыярга һәм ничек итеп киптерергә кирәклеген белергә тиеш. Хәзер ямьле җәй айлары бара, шуңа күрә бергәләп бу мәгълүматны искә төшерик!

Һәрбер дару үләненең үз җыю вакыты бар. Нәкъ менә шул вакытка ул кирәкле файдалы элементларны үзендә туплап бетергән була.

### Бөреләр

Әгәр дә сүз бөреләр турында барса, аларны яз башыннан ук җыя башларга кирәк. Кайбер үсемлекләрдә ул февраль азакларына ук туры килә. Бөреләрнең бөрткән чагын туры китерергә кирәк, әмма алар әле ачыла башламаган булырга тиеш. Әгәр яфрак чыга башлаган булса, соңга калган булып санала, алар инде дару кебек кулланыла алмыйлар.

### Кайры

Куакларның һәм агач кайрыларын шулай ук яз көне – су пәйда булгач җыя башлыйлар. Беренче яфраклар күренә башлау белән, аларны җыю туктала. Әгәр дә кайры дөрес периодта җыелса, ул ботактан бик җиңел аерылырга тиеш.

### Яфраклар

Чәчәк бөреләре күренә башлагач, яфраклар җыела башлый. Бик аз очракта гына җимеш формалаша башлагач җыела. Ә кайбер кышкы (нарат җиләге, турак уты) агачларныкын көз көне дә, уңыш алгач, җыйсаң була.

### Чәчәкләр

Әгәр дә дару буларак үләннең чәчәге кирәк булса, аны тулысынча чәчәк аткач җыялар. Кайчакларда чәчәк бөресен дә кулланалар, әмма шиңә башлаган чәчәкләрне беркайчан да дару буларак кулланмыйлар.

### Үләннәр

Берьеллык һәм күпьеллык үләнле үсемлекләрнең җир өстендәге өлешен чәчәк аткан чагында яисә чәчкәгә бөреләнгән чагында җыялар.

### Орлыклар һәм җимешләр

Күп очракларда, җимешләр һәм орлыкларны тулысынча өлгергән вакытларын көтәргә киңәш итәләр. Искәрмәләр дә юк түгел. Мәсәлән, гөлҗимеш нык өлгергән вакытында бик йомшак була һәм җыйган чагында изелә. Шуңа да аларны азрак кына пешеп җитмәгән вакытында җыялар. Балан, миләш, сырганакны беренче кыраулардан соң җыю яхшы.

Әгәр дә үсемлекләрнең орлыклары өлгереп, коела башласалар, азрак хәйләләп, мондый алым кулланалар: орлык өлгерә торган ботакка киндер тукымадан кечкенә капчык кидертеп, җил белән очып китмәслек итеп бәйләп куялар. Әзер булган орлыклар үзләре шунда җыелалар.

### Тамырлар, тамыр-сабаклар, бүлбеләр һәм суганчалар

Аларны, кагыйдә буларак, иртә язда, ягъни үсемлекләр уянган чагында, ә кайберләрен исә көзен – җир астында файдалы матдәләр күп җыелган вакытта казып алалар. Көзен җыйган вакытта, гадәттә, үсемлекнең җир өстендәге өлеше кибә башлаган вакытын көтәләр, ләкин тулысынча кибеп, корыган вакытка кадәр түгел, чөнки ул чагында үсемлекнең төрен билгеләү авырлаша.

### Дару үләннәрен ничек дөрес җыярга?

Моның әһәмияте вакытка гына бәйле түгел. Үләннәрне дөрес итеп җыярга кирәк, ягъни үсемлеккә дә зыян китермәскә һәм үләннәрнең файдалы үзлекләрен дә саклап калырга. Гомуми кагыйдә буларак, үсемлекләрнең җир өстендәге өлешен, бигрәк тә чәчәкләрне коры һава шартларында җыялар. Чык төшкән вакытны көтегез, аннан соң инде җыярга мөмкин. Составында эфир майлары булган үсемлекләрне эссе, кояшлы көннәрдә, ә җиләк-җимешләрне һәм сусыл җимешләрне иртә белән яки кичен җыярга киңәш итәлә.

Үләннәр җыярга барганда үзең белән кайчылар, үткен бакча кайчысы (секатор), пычак алырга кирәк. Сабакларны кул белән өзәргә ярамый, чөнки болай эшләгәндә үсемлеккә зыян китерү ихтимал, шулай ук, тамыры белән йолкып чыгару яки сындыру куркынычы бар. Саклык белән генә үзебезгә кирәк өлешне кисеп алырга кирәк.

**Истә тотыгыз:**

*беркайчан да сирәк очрый торган үсемлекләрнең (бигрәк тә Кызыл китапка кертелгәннәренең) тамыр-сабакларын казып алырга ярамый;

*күргән барлык үсемлекләрне дә җыеп бетерергә кирәкми, чөнки алар киләчәктә дә үсәргә һәм күбәергә тиешләр;

*әгәр дә сабаклары яки чәчкәләре генә кирәк булган очракта үләнне тамыры белән йолкып алырга ярамый.

### Кайбер төрләрнең җыю нечкәлекләре

Вакыт кебек үк, әзерләү ысуллары күп очракта чималның төренә дә бәйле. Без белергә тиеш булган кайбер нечкәлекләрне карап үтик.

### Бөреләр

*каен бөреләрен әзерләгәндә, иң элек ботаклары белән бергә кисеп алалар, кипкәннән соң сугып, төрле катышмалардан чистарталар;

*нарат бөреләрен үткен пычак белән кисеп алалар, ә усак һәм кара тирәк бөреләрен куллар белән сак кына өзеп алалар.

### Кайры

*яшь (3-4 яшьтән артмаган) ботакларның һәм кәүсәләрнең кайрыларын җыялар;

*җыяр өчен кайрының яшь һәм шома булганы кулайрак, чөнки карт кайрыларда файдалы матдәләр аз була;

*имән кайрысы кәүсәсеннән түгел, ә ботактан алына;

*ялгышмас өчен, яхшы белгән үсемлекләрнең генә кайрыларын җыярга кирәк (кайры җыю вакыты үсемлектә әле яфраклар күренмәгән вакытка туры килә).

### Яфраклар

*яфракларны кул белән өзәләр яисә кайчылар (бакча кайчысы) белән кисеп алалар;

*калын сабакларны яфраклардан аерырга киңәш итәләр, чөнки аларда файдалы матдәләр юк диярлек, ләкин алар яфракларның кибүен тоткарлыйлар;

*төрле корткычлардан зыян күрмәгән, сәламәт яфракларны җыялар;

*кечкенә яфракларны (нарат җиләге, турак уты) ботакчыклары белән бергә җыялар, аннан соң алардан аералар;

*саклау өчен ботакның түбәнге һәм урта өлешендә булган яфракларын җыю хәерле.

### Чәчәкләр

*чәчәкләрне кайчы белән кисәләр яки саклык белән чәчәк сабагын өзеп алалар;

*чәчәкләрне җыйган вакытта кечкенә кәрзиннәр кулланырга киңәш ителә.

### Үләннәр

*сакларга әзерләгән вакытта үсемлекләр җир өстендәге өлешен кисеп алалар һәм аскы яфраклары биеклегендә чабалар;

*озын буйлы, калын сабаклы үсемлекләрдә (әрем һ. б.) сабакның өске өлешләрен (15-20 см) һәм ян-яктагы тармакларын алалар.

### Орлыклар һәм җимешләр

*орлыкларны һәм җимешләрне сайлап алып җыялар, чөнки алар бертигез өлгермиләр;

*коела торган орлыклы үсемлекләрне (әнис, кориандр, тмин һ. б.) өлгереп җитмәгән орлыклары белән өске өлешен кисеп алалар, бер бәйләмгә бәйлиләр һәм кибәргә элеп куялар;

*сусыл җимешләрне (каен җиләге, карлыган, караҗиләк) саклык белән җыялар. Җиләкләрнең һәрбер катына яфраклар җәяләр. Болай эшләгәндә алар бер-берсенә ябышмыйлар, изелмиләр.

### Тамырлар, тамыр-сабаклар, бүлбе һәм суганчалар

*үсемлекләрнең җир астындагы өлешен көрәкләр ярдәмендә туфрагы белән бергә казып алалар, чистартып, салкын су белән юып алалар;

*юганнан соң киптереп, вак тамырчыклардан арындыралар;

*лайлалы матдәләре булган үсемлекләрнең (төертамыр) җир астындагы өлешен юарга ярамый. Аны саклык белән туфрактан арындыралар һәм тамырларыннан (бүлбе, тамыр-сабакларыннан) өске катын алалар.




# Татарстан Диния Нәзарәтенең «Хозур» нәшрият йорты Габдрахман Карабашиның «Китәбүт-тәҗвид» хезмәтен бастырды

Тәүге тапкыр әлеге китап XX йөз башында дөнья күреп, күп кенә төрки халыклар арасында таралган булган.

«Китәбүт-тәҗвид»тә кыскача тәҗвид (Изге Коръәнне уку кагыйдәләре) аңлатыла, авазларның мәхраҗлары, ягъни дөрес укылышы, әйтелү урыннары тасвирлана.

Китапка гарәп имләсендә Казан шәһәрендә 1906 елда бастырылган текст нөсхәсе һәм аның хәзерге әдәби татар теленә тәрҗемәсе кергән.

**Китапны http://huzurshop.ru сайтыннан яки Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт (РИИ бинасы) адресы буенча урнашкан кибеттән алырга мөмкин.**

**Телефон:** +7 (843) 258-52-01

**Хәләл стандарты буенча медицина чараларын булдыру**

Без сезнең мәнфәгатьләрне кайгыртабыз!

Сораулар буенча мөрәҗәгать итү: Гүзәл +7-927-039-30-09




- Хирургия өлкәсендә булган медик ярдәмнәрне ислам кануннары һәм хәләл сертификаты буенча эшләү
- Ислам университетында хасталар белән ислам кануннары таләп иткән һәм ислам стандартлары белән эшләү буенча белем алган югары квалификацияле табиблар
- Хасталар һәм аларның гаиләсе өчен булган шәхси бүлмә, намаз уку бүлмәсе, оптималь санитар-гигиена шартларын булдыру
- Ашау-эчү хәләл сертификаты таләпләре белән расланган

Сәламәтлек өчен каршылыклар бар,белгеч белән киңәшләшү мөхим

www.drkbmzrt.ru
г.Казань, Оренбургский тракт, 140

*С заботой о каждом ребенке!*

## Мөселман яшьләре форумында катнашырга ашык!

Борынгы Болгар җирлегендә алтынчы тапкыр Мөселман яшьләре форумы уздырылачак. Әлеге форум 22 июньнән 29 июньгә кадәр узачак.

Форумда катнашучылар өчен кайбер таләпләр бар: алар 18-35 яшьлек булырга, ни өчен форумга барасылары килү турында #фмм_6 хештегын куеп социаль челтәрләрдә хәбәр урнаштырырга, форумны оештыручылар тарафыннан әзерләнгән тестны башкарырга тиеш булалар. Тулырак мәгълүмат https://vk.com/fmm_6 төркемендә яисә ТР МДН сайтында.

**КАЗАН ӨЧЕН ИЮЛЬ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ**

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Сәхәр тәмам | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.07.2018 | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 12:00 | 17:34 | 20:31 | 22:01 |
| 02.07.2018 | 01:03 | 01:33 | 03:03 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 03.07.2018 | 01:04 | 01:34 | 03:04 | 12:00 | 17:34 | 20:30 | 22:00 |
| 04.07.2018 | 01:05 | 01:35 | 03:05 | 12:00 | 17:33 | 20:29 | 21:59 |
| 05.07.2018 | 01:06 | 01:36 | 03:06 | 12:00 | 17:33 | 20:28 | 21:58 |
| 06.07.2018 | 01:07 | 01:37 | 03:07 | 12:00 | 17:33 | 20:27 | 21:57 |
| 07.07.2018 | 01:08 | 01:38 | 03:08 | 12:00 | 17:33 | 20:27 | 21:57 |
| 08.07.2018 | 01:10 | 01:40 | 03:10 | 12:00 | 17:32 | 20:26 | 21:56 |
| 09.07.2018 | 01:11 | 01:41 | 03:11 | 12:00 | 17:32 | 20:25 | 21:55 |
| 10.07.2018 | 01:12 | 01:42 | 03:12 | 12:00 | 17:31 | 20:24 | 21:54 |
| 11.07.2018 | 01:13 | 01:43 | 03:13 | 12:00 | 17:31 | 20:23 | 21:53 |
| 12.07.2018 | 01:15 | 01:45 | 03:15 | 12:00 | 17:30 | 20:22 | 21:52 |
| 13.07.2018 | 01:16 | 01:46 | 03:16 | 12:00 | 17:30 | 20:21 | 21:51 |
| 14.07.2018 | 01:17 | 01:47 | 03:17 | 12:00 | 17:29 | 20:19 | 21:49 |
| 15.07.2018 | 01:19 | 01:49 | 03:19 | 12:00 | 17:29 | 20:18 | 21:48 |
| 16.07.2018 | 01:20 | 01:50 | 03:20 | 12:00 | 17:28 | 20:17 | 21:47 |
| 17.07.2018 | 01:22 | 01:52 | 03:22 | 12:00 | 17:27 | 20:16 | 21:46 |
| 18.07.2018 | 01:23 | 01:53 | 03:23 | 12:00 | 17:27 | 20:14 | 21:44 |
| 19.07.2018 | 01:25 | 01:55 | 03:25 | 12:00 | 17:26 | 20:13 | 21:43 |
| 20.07.2018 | 01:26 | 01:56 | 03:26 | 12:00 | 17:25 | 20:11 | 21:41 |
| 21.07.2018 | 01:28 | 01:58 | 03:28 | 12:00 | 17:24 | 20:10 | 21:40 |
| 22.07.2018 | 01:30 | 02:00 | 03:30 | 12:00 | 17:24 | 20:08 | 21:38 |
| 23.07.2018 | 01:31 | 02:01 | 03:31 | 12:00 | 17:23 | 20:06 | 21:36 |
| 24.07.2018 | 01:33 | 02:03 | 03:33 | 12:00 | 17:22 | 20:05 | 21:35 |
| 25.07.2018 | 01:35 | 02:05 | 03:35 | 12:00 | 17:21 | 20:03 | 21:33 |
| 26.07.2018 | 01:37 | 02:07 | 03:37 | 12:00 | 17:20 | 20:01 | 21:31 |
| 27.07.2018 | 01:38 | 02:08 | 03:38 | 12:00 | 17:19 | 20:00 | 21:30 |
| 28.07.2018 | 01:40 | 02:10 | 03:40 | 12:00 | 17:18 | 19:58 | 21:28 |
| 29.07.2018 | 01:42 | 02:12 | 03:42 | 12:00 | 17:17 | 19:56 | 21:26 |
| 30.07.2018 | 01:44 | 02:14 | 03:44 | 12:00 | 17:16 | 19:54 | 21:24 |
| 31.07.2018 | 01:46 | 02:16 | 03:46 | 12:00 | 17:14 | 19:52 | 21:22 |

**ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ**
*Июнь саны, №6 (275)*

Баш мөхәррир: **Сәмигуллин К. И.**
Мөхәррир: **Шафикова Р. Р.**
Дизайнер: **Даутов Р. А.**
Яңартылган логотип авторы: **Димасов Э. И.**
Биткә салучы: **Сәйфетдияров Р. Г.**
**Редакциянең һәм нәшер итүченең адресы:**
420111, Казан шәһәре, Лобачевский ур., 6 нчы йорт
**Электрон адресы:** shura@huzur.ru
**Телефон:** +7 (843) 598-09-42

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе
**Камил СӘМИГУЛЛИН;**
«Хозур» нәшрият йорты директоры
**Ришат ХӘМИДУЛЛИН**;
ТР МДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе
Булат МӨБӘРӘКОВ;
Татарстанның баш казые
**Җәлил ФАЗЛЫЕВ;**
ТР МДНнең Голәмәләр шурасы әгъзасы
**Габдулла ӘДҺӘМОВ**

**Гамәлгә куючы:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте
(420024, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 38).
**Нәшир:** «Хозур» нәшрият йорты
(420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6 нчы йорт)

Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды
(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2)
Тираж: 5 мең данә Заказ №2750
Газетага ярты елга язылу бәясе – 132 сум. Казан шәһәренең мәчетләрендә 27 нче июньдә таратыла.
График буенча бу санга 26 нчы июнь көнне 21.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды: 21.00 сәгатьтә.